Рафикъ МАРДАНОВ

# Заманым сагышлары

ШИГЫРЬЛӘР ҖЫЕНТЫГЫ



Рафикъ МАРДАНОВ

# *ЗАМАНЫМ САГЫШЛАРЫ*

## *ШИГЫРЬЛӘР ҖЫЕНТЫГЫ*

2010 ел



**Марданов Рафикъ Шайхлислам улы** Башкортостанның Аскын районында урнашкан Олы Елга авылында 1942 нче елның 27 гыйнварында туа. Әлбәттә, бу авыр чак: сугыш, ачлык-ялангачлык. Гаиләдә алты бала. Өстәвенә әнисе, Мәрзикә ханым, җәй житкәч, урак өстендә тиф чире белән чирләп вафат була.

Әтисе Шайхлислам сугышка алынмый. Ул, балта остасы буларак, колхозның барлык каралтыларын ремонтлап йөри, бура чаба. Иртән чыгып китә - төнлә кайта. Ятим калган баланы апасы карый. Ә аңа, апасына, үзенә дә бары 13 яшь. Тик аны да төрле эшкә куша башлыйлар: фермада бозау карарга, сыер саварга. Тора-бара урман эшенә дә алып китәләр.

Рафикъ ашаса ашый, ашамаса - шул килеш йоклап китә... Шулай да барлык авырлыкларны җиңеп үсә, гармунда уйнарга өйрәнә. Апасы кияүгә чыккач аларда яши, башлангыч мәктәптә җизнәсендә укый. Һәм бервакыт үсеп егет була, армиягә китеп хезмәт итеп тә кайта.

Күп еллар Асбест шәһәрендә яши һәм эшли, өйләнә. Туган якларына кайтып, Башкортостан республикасында, Яңавыл шәһәрендә яши башлый. Анда 25 ел шофер булып эшли, начальствоны йөртә. 50 яшендә, Асбестта эшләп алган “вредный“ стаж ярдәмендә, пенсиягә чыга.

Азмы-күпме вакыт үткәч шигырьләр яза башлый. Аларда сагыш, моң. Сез дә укыгыз, белегез.

Ильдар НУРИСЛАМОВ,
журналист.

## Без яшәгән еллар

Онытылмас алар,
Без яшәгән еллар –
Кырыгынчы сугыш еллары.
Утлар-сулар кичкән,
Ач-ялангач үскән,
Сабан сөргән сабый коллары.
Кырда башак җыйган,
Борчак ашап туйган
Туган илнең ятим уллары.

Биреп барлык көчен
Туган иле өчен,
Ялкын булып эштә яндылар.
Җирдә күмер кисеп,
Күкнең серен чишеп,
Йолдызларга юллар салдылар.
Кырда иген игеп,
Авырлыкны җиңеп,
Туган илгә тугры калдылар.

Онытылмас алар
Алтмышынчы еллар,
Маяк булып мәңге янарлар.
Күпме еллар үтәр,
Кеше күккә китәр –
Башка дөнья эзләп табарлар.
Килер буын үсәр,
Алар шунда күчәр –
Безнең эзләр җирдә калырлар.

## Аскын жире

Изге Аскын жире,
Газиз туган җирем,
Туып үскән алтын бишегем.
Тәүге тапкыр җиргә
Басып яланаяк
Ачып кергән дөнья ишегем.
Күпме каршы алды,
Күпне озатып калды
Үз җирендә минем ишене.

Кайнап чыккан шифа
чишмәләре белән
Җир йөзенә даны таралган.
Агым Төй буенда,
Җылы куенында –
Кайнар каным шунда яралган.
Шигыремны язмый,
Аны җырга салмый
Мин битараф булып калалмам.

Онытырлык түгел
җәйге табигате,
Кар бураны, кара урманы.
Юл буенда үскән
Шомыртлары пешкән,
Борма-борма урман юллары.
Тәнгә җанын өргән,
Җанга җылы биргән
Туган якның җылы юрганы

## «Кителеп» төште кояш

**Аяз көнне яшен сукты,**
**«Кителеп» төште кояш**
**Бер-бер артлы биш туганым**
**Тезелеп дөнья куйгач.**

Алты бала булдык,
Бер анадан тудык,
Бер кашыктан ашап туендык.
Яшьли ятим калдык,
Кайгыларда яндык,
Бер кочакка кереп сыендык.
«Бер казанда кайнап»,
Сәндерәдә аунап,
Бер учакны ягып җылындык.
Артта калды шул чак,
Сүнде янган учак,
Туганнарым күптән гүрләрдә.
Тыштан уйнап-көлеп,
Эчтән янып-көеп,
Ялгыз калып йөрим җирләрдә.
Ялгызлыкка түзми,
Газапларын гизми,
Кереп булмый кара гүрләргә.
«Кителде» Ай-Кояш
Алар дөнья куйгач,
Төн каплады барыр юлымны.
Әгәр ялгыш барсам,
Юлда ялгыз калсам,
Табалмасам эзләп юлымны,
Ий, Ходаем Аллам,
Өмет итәм алдан,
Сузарсың, дип, ярдәм кулыңны.

## Чатлы каен

**Туган нигез – җанга газиз**
**«Гүр» газабын чиксәң дә,**
**Изге туфрагы тарта**
**Кайда гомер итсәң дә.**

Газиз туган нигеземдә
Үсә бер чатлы каен.
Нигез каенын күрергә
Кайтып булмый ел саен.
Газиз каен, ялгыз каен –
Яшәсен авылкаем,
Туып үскән нигеземне
Саклыйсың, каенкаем.
Ташлап киткән нигез ташын
Ташлама, авылкаем,
Җәйләр булып таулар аша
Кайтырмын табып җаен.
Кисмәгез чатлы каенны:
Чатлы каен шатлыкка,
Ялгыз булса да пары бар –
Бирешми ул картлыкка.
Чатлы каен, бик карт каен –
Үсә нигез чатында,
Шул каенны кайтып күрәм
Бик сагынган чагымда.
Кисмәгез тиңдәш каенны
Туган нигез хакына,
Истәлеккә үссен каен
Бөтен туган-затыма.

**Аскын районы Олы-Елга авылында дан тоткан сукыр гармунчы мәрхүм Фәйзер абзыйга багышлыйм.**

## Куяр идем заман һәйкәлен

Бу дөньяда изге кеше булып
СаклANAсың минем хәтердә.
“Атказанган” дигән даның калды,
Тарих булып безнең дәвергә.
Яшәдең син гомер буйларыңа,
Дучар булып ачы язмышка,
Сабышмады якты хыялларың
Дөм караңгы кара сагышка.
Авыр заман – сугыш елларында
Тальяныңны сузып уйнадың,
Авыл кичләрендә һәрбер өйгә
Яңгырады гармун моңнарың.
Гармуныңны алып кулларыңа
Йөрдең син аулак өйләргә,
Клубларда тузан очып торды
Син уйнаган бию көйләргә.
Син утырган чаналарга – кызлар
Кулъяулыклар чигеп тактылар,
Кыңгыраулы гармун көйләренә
Җиккән атлар ярсып чаптылар.
Озак еллар буе – гармуныңны
Уйнап үтте гомер көннәрең,
Кулларыңда сандугачлар булып
Сайрадылар гармун телләре.
Тезләреңә алып сабый чакларымда
Гармун бирдең «сабый» кулына.
Бармагымны кулларыңа бәйләп
Моңнар салдың гомер юлыма.

Онытмадым сине, Фәйзер абзый,
Сакланасың күңел түрендә.
Син өйрәткән моңлы көйләреңне
Сакладым мин гармун телендә.
Еракларда калды авылымның
Сукыр күзле Фәйзер еллары,
Исләремнән чыкмый ул уйнаган
Сокланырлык гармун моңнары.
Авылымның үткәннәрен алып,
Язар идем тарих битләрен,
Шул дәвергә, сукыр гармунчыга
Куяр идем заман һәйкәлен.

**Авылым сагышлары**

Сагынамын авылымның
Олы-Елга буйларын,
Яз көнендә суын эчкән
Су буе каеннарын.
Олы-Елга – кече елга –
Төшләремдә күрәмен,
Тугаенда чәчкә җыеп,
Суларында йөзәмен.
Сагындыра авылымның
Айлы зәңгәр кичләре
Урам буйлап яңгыраган
Тальян гармун хисләре.
Олы-Елга – моңлы елга,
Төшләремдә күрәмен,
Айлы кичтә гармун уйнап
Урамыннан үтәмен.
Киләә туган авылымның
Саф суларын эчәсем.

Сагындыра тау астыннан
Чылтырап аккан чишмәсе.

Олы-Елга – кече елга –
Төшләремдә күрәмен.
Тау астыннан агып чыккан
Чишмә суын эчәмен.

Сагындыра киң кырлары,
Юллары, урманнары.
Җәй көнендә үлән үскән
Ямь-яшел урамнары.

Олы-Елга – кече елга–
Төшләремдә күрәмен,
Бала чагым – яланаяк
Урамнан йөгерәмен.

## Мин бит гармунчы идем

Гомерем буе кулларымнан
Гармунымны куймадым,
Моңга салып гармунымны,
Җырларымны җырладым.
Бала чакларымнан алып
Тальянымны уйнадым,
Хромкасын, баянын да –
Берсен дә калдырмадым.
Уйнадым мин матур итеп,
Дәрт биреп күңелләргә,
Кичләрендә маяк булдым,
Кызлар һәм егетләргә.
Уйнадым зар- моңлы итеп
Көч биреп беләгемә.
Шулай итеп моңнар салдым,
Моңсызлар йөрәгенә.

Сыздырып уйнап йөредем
Кичләрен урамнарда,
Язын-көзен, җәен-кышын,
Нык ачы бураннарда.
Әле дә мин гармунымны
Аламын кулларыма,
Ул бит миңа юлдаш булды
Гомерем буйларына.

## Урман юллары

**Каюм авылы һәм Агарзя станциясе юлларына багышлыйм.**

Урман аша сузылганнар
Авылымның юллары,
Урман юлларыннан узды
Яшьлегемнең еллары.
Урман буйлары,
Урман юллары,
Шул юлларда яшьнәп узды
Яшьлек еллары.

Яшьлегемнең җил-давыллы,
Катмарлы елларында
Алып китте мине язмыш
Урманым юлларыннан.
Урман буйлары,
Урман юллары,
Шул юлларда торып калды
Яшьлек еллары.

Бик еш керә төшләремә
Урманымның юллары,

Шул юлларны онытмыйлар
Гомеремнең еллары.
Урман буйлары,
Урман юллары,
Шул юлларны җуялмыйлар
Гомер еллары.

Кайтыр идем урманыма,
Урманым юлларына,
Барыр идем шул юллардан
Яшьли сөйгән ярыма.
Урман буйлары,
Урман юллары,
Еракларда торып калды
Яшьлек елларым.

## Төй кызлары

Саф күңелле чакларымда,
Яшьлегем язларында,
Тәүге тапкыр күзем төште
Төй буе кызларына.
Зифа буйларына карап,
Сокландым күзләренә,
Кояш нурлары сибелгән
Оялчан йөзләренә.
Озата бардым Төй кызларын
Язгы май кичләрендә,
Йомшак кына кулым салып
Неп-нечкә билләренә.
Уйнадым мин гармунымны
Төй кызлары көенә,
Унлы лампалар кабызып,
Кичен аулак өендә.

Җыелдык кичке уенга,
Ямьле, айлы кичләрдә,
Төй кызлары биеделәр
Мин уйнаган көйләргә.
Яраттым мин Төй кызларын,
Сөйдем дә, назладым да,
Йөрәгемә ут кабыздым
Яшьлегем язларында.

## Төй буе сагышлары

Ятим бала чакларымның
Афәтле елларында
Алып килде мине язмыш
Төй суы буйларына.
Бер күрүдә гашыйк булып,
Төштем Төй буйларына,
Каз бәпкәләрен йөздердем
Топ-тонык суларында.
Кармакларымны күтәреп,
Йөрдем җәй айларында
Ә кичләрен учак ягып
Утырдым тугаенда.
Су чәчрәтеп, уйнап-көлеп,
Йөздем саф суларында,
Шаулап үтте бала чагым
Агым Төй буйларында.
Тальянымны кулыма алып,
Йөредем ярларында,
Төй буйлары шаһит булды
Яшьлегем таңнарына.
Уйнадым мин гармунымны
Биреп яшьлек хисләрен.

Яңгыратып Төй буйларын,
Җәйге ямьле кичләрен.
Йөрдем яшел тугаенда,
Язгы сабан туенда.
Гөрләп үтте минем яшьлек
Төй елгасы буенда.
Исләремдә Төй суының
Борылып агышлары,
Йөрәгемә тынгы бирми
Төй буе сагышлары.
Бик сагындым су буйларын,
Чәчкәле тугайларын,
Ахун авыл, Каюм, Истәк –
Төй буе авылларын.
Кайтыр идем язларында
Язгы сабан туйларга,
Барыр идем Төй буена,
Төй моңнарын тыңларга.
Кайтыр идем яшьлегемә,
Төй буе җәйләренә,
Уйнар идем гармунымны
Яшьлегем көйләренә.

## Бала чагым

Исләремдә шаян бала чагым –
Кышларында чаңгы шуганым,
Урман буе – яшел аланнарда
Балтырганнар ашап туйганым.
Көтеп алып җиргә яз килгәнен,
Назландым мин язгы җилләрдә,
Яланаяк «ала карлар» ерып
Йөгереп чыктым язгы чирәмгә.

Кырык ямау – киндер күлмәк киеп,
Китә идем азык эзләргә,
Басу кырларында башак җыеп
Кайта идем соңгы көзләрдә.
Җылы җәйнең аяз көннәрендә
Каенлыкка бардым уйнарга,
Хәтфә үләннәрдә ятып аунап
Пешкән җиләкләрен җыярга.
Яраттым мин җәйге су буйларын
Сандугачлар сайрап торганга.
Яр буенда үскән зирекләрнең
Очларына менеп җырларга.
Чыбыркылар үреп – җыен бала-чага
Бара идек көтү көтәргә,
Каенлыкта, җылы учак ягып
Уйнадык без көзге кичләрдә.
Кыш көнендә өйдә ямансулап
Утыра идем тәрәз төбендә,
Өсләремдә кием булмаганга
Туры килде җәйне көтәргә.
Ятимлектә үтте шаян бала чагым,
Булмады шул әнкәм сөяргә,
Авырудан яшьли мәрхүм булды,
Барып керде салкын гүрләргә.
Моңлы булып үстем бала чактан,
Моңлы булды минем җырларым,
Әллә инде ятимлектән шулай
Моңсу бага әле дә күзләрем.
Сагынамын бала чакларымны,
Ничек кенә авыр булса да,
Исләремнән чыкмый сабый чагым,
Әллә күпме еллар узса да.

Һич онытмыйм бала чакларымны,
Тәүге хисләр әле дә сүнмиләр,
Әле булса колак очларымда
Кыңгыраулар булып чыңлыйлар.

**Гармун белән хушлашу**

Бөтен гомеремнең буйларына
Гармун булды өем түрендә,
Гармун уйнап, матур җырлар җырлап
Яшәдем мин дөнья йөзендә.
Сагыш тулы моңлы көннәремдә,
Кузгалганда хисләр күңелемдә
Шул гармуным миңа юлдаш булды, –
Дус булдык без бергә гомергә.
Үтте айлар, үтте озын еллар – ,
Назлы җырлар уйнап җырладым.
Моңнар акты ташып йөрәгемнән –
Гомер агышларын тоймадым.
Кабатланмас уртак хисләр белән
Сизмәгәнмен гомер үткәнен.
Аерылмас дустым, гармун белән
Хушлашырга вакыт җиткәнен.
Яшәдек без икәү, гармункаем,
Бер-беребезне назлап, иркәләп,
Нинди генә куллар сине хәзер
Бармаклары белән өзгәләр?
«Сайрамассың» инде, гармункаем,
Ямьле җәйнең назлы кичләрен,
Онытырсың инде мин булмагач
Йөрәгемнең моңлы хисләрен.

**Күршемә**

Урам аша күршедә
Яши иде бер кеше –
Тирә-юньдә атказанган
Гармунчы булды үзе.
Шадра йөзле, йомык күзле,
Дөм сукыр иде үзе,
Кыска буйлы, ябык кына,
Фәйзер исемле кеше.
Эшләде ул бөтен эшне –
Белмәгәне булмады,
Утын кисте, утын ярды,
Мин сукыр дип тормады.
Җәй көнендә бакчасында
Тәмәкесен үстерде,
Җыеп алып, җепкә тезеп
Чоланында киптерде.
Шөшле алып, юкә ярып
Чабатасын ясады,
Агач ялгашына салып
Тәмәкесен тапады.
Тәрәзә ачып җәй көнендә
Белмим, нидер күзәтте.
Гәҗит битләренә төреп
Тәмәкесен көйрәтте.
Йөреде ул базарларга
Чабатасын сатарга,
Менә шулай акча җыйды
Яңа гармун алырга.
Яшәде ул күңел ачып,
Якты булды хыялы,
Аның гармун көйләренә
Бөтен авыл җырлады.

**Авылым кочагында**

Мең тугыз йөз кырык ике –
Дөньяга килгән елым,
Җылы кочагына алды
Авылым туган улын.
Тәүге тапкыр сулыш алып
Тирбәндем бишегендә,
Кинәт кенә ятим калдым
Җәйләрнең бер кичендә.
Ятимлеккә карамыйча
Тырыштым мин үсәргә,
Шулай итеп тәпи басып
Йөгердем идәннәрдә.
Йөгереп чыктым урамнарга,
Йөгердем кырларына,
Зәңгәр күбәләкләр кудым
Чәчкәле болынында.
Авылымны бик яраттым,
Сыендым кочагына,
Шул кочакларда назландым
Бала-чага чагымда.
Гашыйк булдым урманына,
Басу һәм кырларына,
Яланаяк йөгереп төштем
Җәйге су буйларына.
Су буйлары бигрәк ямьле –
Таллар үсә ярында,
Каз канатларын җыйдым мин
Җәйнең матур аенда.
Көз көнендә көлтә җыйдым
Коры чокыр тавында,

Йөгерә-йөгерә атлар кудым
Әвен суккан чагында.
Кыш көнендә чаңгы шудым
Аркабаш тауларында,
Җәй аенда менеп чаптым
Җилкән тай – атларында.
Уйнап-көлеп чана шудым
Базанчат тауларында,
Мәктәбендә белем алдым
Укыган чакларымда.
Менә шулай иркәләдең,
Назладың куенында,
Онытa алмыйм, авылкаем –
Һәрчак син уйларымда.

## Иркәмә

Очраштык, иркәм, синең белән
Матур табигатьтә – язлар аенда,
Җылы яктан кошлар очып кайтып
Ояларын корган чагында.
Очраштык без синең белән
Яз көнендә, сулар ташканда,
Агыйделнең биек ярларыннан
Кар сулары шаулап акканда.
Исеңдәме, иркәм, икәү бергә
Йөргән идек Идел ярында,
Бер-беребезгә кул бирешеп
Менгән идек аның тавына.
Карлугачлы биек кыясына басып
Сокландык без кичке Иделгә,
Алсу-зәңгәр хозурлыкка хәйран калып
Изге хисләр тулды күңелгә.

Хәтерлимсең, иркәм, яз көнендә
Язгы сукмаклардан үткәнне,
Кар астыннан чыккан тәүге чәчкәләрне
Өзеп алып бүләк иткәнне.
Идел буе тал-тирәкләр, бөре исе
Кузгаттылар күңел хисләрен,
Исләремдә хаман бергә йөргән заман,
Нурын гизеп язгы кичләрнең.
Бик сагынам, иркәм, шул чакларны,
Онытылмаслар алар гомергә,
Миңа булган синең изге хисләр
Мәңге калыр минем күңелдә.
Рәхмәт сиңа, иркәм, мең рәхмәт,
Чын күңелдән өзелеп сөйгәнгә,
Озак еллар миңа юлдаш булып,
Ахыргача тугры булганга.

## Апа белән җизнәмә

Замананың җилләренә каршы торып
Гомер йомгакларын бергә сүттегез,
Күңел канатларын сындырмыйча
Тормыш юлын бергә үттегез.
Сабыр күңел, төпле акыл белән
Тормыш давылларын җиңдегез,
Башкаларга өлге-үрнәк булып
Намус белән гомер иттегез.
Сынаса да сезне авыр еллар
Үз баладай мине күрдегез,
Күңелләрем өшегәндә җылы бирде
Сезнең әйткән җылы сүзегез.
Тәмле булды пешкән ашларыгыз,
Якты булды сезнең йөзегез,

Мәңгелеккә исләремдә калды
Акыл биргән яхшы сүзегез.
Сабый чакта олы терәк булып
Өндәдегез тугры юлларга,
Үсеп җиткәч адашмаслык итеп,
Озаттыгыз озын елларга.
Минем өчен әти-әни булып
Калдыгыз сез мәңге күңелдә,
Сезнең биргән изге киңәшегез
Дәва булды бөтен гомергә.
Тыныч булсын килер көннәрегез,
Озак яшәгез дөнья йөзендә,
Сезнең шулай исән-имин булу
Зур бәхет ул минем өчен дә.

## Гөлсинә

Бик тә уңган һәм матур кыз
Яши минем күршедә:
Тирә-якка ямь, нур өстәп
Гөл үстерә Гөлсинә.
Әй Гөлсинә, Гөлсинә,
Күзләрем төште сиңа.
Гөлбакчамда чәчкә аткан
Алсу гөлләрем сиңа.
Иртә торып гөлләренә
Сулар сибә Гөлсинә,
Аның көләч йөзләренә
Кояш нурларын сибә.

Минем күрше Гөлсинә
Бик сөйкемле күренә,

Бакчадагы гөлләрем дә
Аңа таба үрелә.

Сулар сибеп үстерәмен
Сусаган гөлләремне,
Күрше кызы яулап алды
Бушаган йөрәгемне,
Күрше кызы басар әле
Ярсыган йөрәгемне.
Әй Гөлсинә, Гөлсинә,
Күзләрем төште сиңа.
Гөлбакчамда чәчкә аткан
Алсу гөлләрем сиңа.

## Малай-шалайлар

Узды еллар, керде яңы гасыр.
Хәзер инде без карт бабайлар,
Сугыш уеннарын уйнап үскән
Ач корсаклы малай-шалайлар.
Кырыгынчы сугыш елларының афәтләрен
Ил күргәнне бергә күрделәр,
Унбер яштән пар ат җигеп,
Ирләр булып сабан сөрделәр.
Ачы бураннарда чана тартып
Утын ташып кисеп өйделәр,
Юкә агачыннан юкә ярып
Чабаталар үреп киделәр.
Ә кичләрен, дәрес әзерләгәч,
Шул юкәдән баулар иштеләр,
Бер метрдан алып үлчәүләргә салып
Киләп ясап бәйләп тезделәр.

Ягылмаган мәктәп эчләрендә
Туңа иде язган каралар...
Ач-ялангач килеш укыдылар
Кырыгынчы елгы сабый балалар.
Күз күннәрен каен агачыннан
Тимераяк ясап бозда шудылар
Ә язларын «таш табан» дип чабатага
Күтәртмәләр бәйләп куйдылар.
Кар сулары эреп аккан чакта
Иңнәренә биштәр астылар,
Яланаяк басу җирен казып
Черек бәрәңгеләр җыеп кайттылар.
Җигелделәр алар арба-чаналарга,
Төяделәр печән-саламнар,
Авыр тормыш йөген сөйрәп үсте
Кырыгынчы елгы үсмер малайлар.
Чыныктылар алар сугыш чорларында,
Кырыгынчы еллар үтеп киттеләр,
Тоткан җирдән тимер сындырырдай
Егет булып үсеп җиттеләр.
Кызганмыйча биреп яшьлек көчен
Маңгай тирен азмы түктеләр.
Туган илгә олы терәк булып
Намус белән хезмәт иттеләр.
Авызлыклап авыр замананың,
Дилбегәсен кулга алдылар,
Хәтта биек һаваларга менеп
Йолдызларга юллар салдылар
Әле булса алар бирешмиләр,
Өмет белән алга карыйлар;
Сафта әле алар – аксакаллар,
Кырыгынчы елгы малай-шалайлар.

## Үлчәүчеләр

**Ялган үлчәгән кешенең**
**Йомры була башы,**
**Ашаганы – хәрам ашы –**
**Бәндәләрнең каргышы.**

Саткан товарларын мактап
Матур сүзләр сөйлиләр,
Хикмәт табып – җиңел якка
Үлчәүләрен көйлиләр.
Үлчәүчеләр ким үлчиләр,
Ким булганын «күрмиләр»:
Җиңел үлчәп җиңел яши –
Бу хәрам дип тормыйлар.
Килемнәрен үлчәгәндә
Бу гөнаһтыр димиләр,
Кылган бу гөнаһларының
Кимәлләрен белмиләр.
Уйламыйлар үлчәүчеләр
Гамәлләрен язасын,
Гамәл язган дәфтәрләрен
Үлчәүләргә саласын.
Хәрам акчаларын тотып,
Асыл кием эзлиләр,
Мәрҗән, алтын, көмеш җыеп,
Бармакларын бизиләр.
Аңламыйлар бу дөньяда
Бар да торып каласын,
Ахирәттә кисәү булып
Тәмугларда янасын.
Аңламыйлар үлчәүчеләр
Дөньяның алдаганын,
Башкаларны алдыйбыз, дип
Үзләре алданганын.

Үлчәүчеләр ялгышалар
– Мәңгелеккә килдек, – дип,
Әмма-ләкин бу дөньяга
Кунак булып килдек бит.
Үлчәүләрне җиңел үлчәп
Җыймагыз матди байлык,
Иман байлыгын туплагыз,
Матди байлык – бер айлык.
Сак булыгыз, үлчәүчеләр:
Үлчәүгә ким салмагыз,
– Дөнья малын җыябыз, дип,
Җәннәттән буш калмагыз.

**Тәртип чыбыгы**

Хәтерлимен бала чакта әтиемнең
«Бисмилла» дип капкан сыныгын,
Матча буйлап түшәм ярыгына
Кыстырылган тәртип чыбыгын.
Хәтерлимен артык шаярганда
Шул чыбыкка күзем төшкәнен,
Исләремә төшми шул чыбыктан
Арт ягыма өлеш төшкәне.
Кыстырылып куйган каен чыбыкның
Вазифасы булды – тәртип сакчысы,
Күз алдында әллә торгангамы
Татымадым тәртип камчысын.
Озак еллар чыбык торды шунда
Хәтерләтеп тәртип билгесен,
Әти миңа үзе үрнәк иде, –
Үзе булды тәртип өлгесе.
Еллар үткәч кенә аңладым мин
Шул чыбыкның бик тә кирәген,

Төпле тәрбиянең чыганагы
Матчадагы чыбык икәнен.
Шул чыбыкның төпле хатирәсен
Саклап килдем бөтен гомергә,
Тәртип нигезенең бер өлеше
Булып калды минем күңелдә.
Онытылган тәртип чыбыклары
Кирәктер ул, бәлки, бүген дә,
Аталардан калган мирас булып,
Торсын иде өйнең түрендә.

## Укытучым Алия апага

Ал чәчәкләр бүләк итәр идем –
Мөмкин түгел Сезне күрергә,
Котлап түгел туган көнегезне –
Килен булып төшкән көненә.
Бала чагым. Авыл урамыннан
Җәй аеның ямьле көнендә,
Гөрләп үткән матур туй мизгеле
Күз алдында әле бүген дә.
Тарантаска җиккән ярсу атлар,
Кыңгыраулы кара дугалар,
Зәңгәр читле алсу кулъяулыклар
Ат башында янып торалар.
Урам буйлап чаба аргамаклар,
Елтырыйлар көмеш дагалар...
Пыр туздырып арттан йөгерәләр
Сез укыткан бала-чагалар.
Капка төпләрендә – авыл халкы,
Хәйран калып карап торалар,
Туй күлмәге кигән яшь киленгә
Ак бәхетләр теләп калалар.

Яңгыратып яшьлек юлыгызны
Җил-давыллар булып үттегез,
Каршыдагы ачык капка аша
Тормыш елларына кереп киттегез.
Алдыгызга салган «йола мендәренә»
Килен булып килеп төштегез,
Күтәрелеп тормыш баскычыннан
Икәү бергә атлап киттегез.
Онытылып калды еракларда
Килен төшкән матур йолалар,
Урамнарда чапмый аргамаклар,
Елтырамый көмеш дагалар.

## Көтәдер аны каен

**Мәрхүм Хәтип абыема арналган.**

Юл буеннан алып кайтып
Утыртты абый каен
Шул каенны кочып алам
Авылга кайткан саен
Әй каеным, каенкаем,
Авылым-авылкаем,
Бала чакларында сине
Утыртты абыйкаем.
Үсеп җитеп чит илләргә
Китте абый яз аен,
Моңсу гына башын иеп
Озатып калды яшь каен.
Яфрак ярып ялгыз каен
Бөреләнә ел саен,
Еллар аша бер әйләнеп
Кайтыр, дип абыйкаем.
Тамчы алкаларын тагып
Матурлана җәй саен

Һәр ел саен абыемны
Көтәдер ялгыз каен.
Көтмә-көтмә, каенкаем,
Авылым-авылкаем,
Җир астыннан юллар юк шул –
Кайталмый абыйкаем.

## Яшел борчак

Борчак басуына менеп
Өзәмен яшелләрен.
Авыр еллар – бала чагым --
Өзелеп ача карын.
Үрелеп үскән яшел сабак
Сабагы саен кузак
Шул кузакның эчләрендә
Тезелгән яшел борчак.
Кузакларын ачамын да
Борчакларын саныймын.
– Каравылчы күрмиме, – дип,
Тирә якка карыймын.
Каеш-камчы төшмәсен дип –
Мин бит әле сабыймын.
Өзеп алып кесәләргә
Тутырам кузакларын,
Кем күрмәгән – шулар белми
Ачлыкның газапларын.
Кесәләремне тутыргач,
Йолкып җыям кочакка,
Култык астыма кыстырып
Алып кайтам борчаклар.
Басуларда ризык эзләп
Үтте шул бала чаклар.

Су буенда учак ягып
Куырдык без борчаклар,
Уйнап-көлеп, борчак ашап
Туйды безнең «корсаклар».
Мәңге калды исләремдә –
Сагындыра шул чаклар.

Кайда калды бала чаклар,
Кесә тулы борчаклар,
Су буенда сүнеп калды
Без кабызган учаклар.

## Дин кызлары

Очрыйлар урамнарда
Яулык бәйләгән кызлар,
Әйтерсең лә алар безгә
Оҗмахтан килгән кошлар.
Йөрәгемә ут кабызды
Дин юлындагы кызлар,
Күк йөзеннән очып килгән
Җир йөзенә йолдызлар.

Кояш кебек балкып тора
Иманлы нурлы йөзләр,
Каш астыннан тыйнак кына
Елмая серле күзләр.

Дин кызлары сирәк алар –
Кемгәдер берәү генә,
Сиздермичә ут салалар
Егетләр йөрәгенә.

Гашыйк булганны сиздереп
Сүз кушам үзләренә,

Сер бирергә ашыкмыйлар
Мәхәббәт сүзләренә.

Дин кызлары әсир итте
Иманлы йөрәгемне
Бәлки Ходай насыйп итәр –
Табырмын сөйгәнемне.
Йөрәгемә ут кабызды
Дин юлындагы кызлар,
Күк йөзеннән очып килгән
Җир йөзенә йолдызлар,
Күк йөзеннән җир йөзенә
Очып төшкән йолдызлар.

**Гадел мөселманга**

Лә иләһә илләаллаһ дип
Иман әйтергә өйрән,
Шул вакытта син булырсың
Мәхәммәд өммәтеннән.
Һәр эшеңне бисмилла әйтеп,
Тапшыр изге Ходайга.
Аның кодрәтләре белән
Барыр эшең уңайга.
Лә иләһә илләаллаһ дип
Сәфәргә чыксаң әгәр,
Ярдәм итеп – мең бәладән
Саклар Ходай Тәгалә.
Белгән догаларны укы
Һәр көн саен кабатлап.
Соңгы сулышыңа кадәр
Яшә син Иман саклап.

Гомерең буе намус саклап
Тугры бул син Иманга,
Биргәненә риза булып,
Шөкер итеп Ходайга.
Иманыңны өстен куйсаң
Һәр эшеңнең башында,
Башың түбәнгә иелмәс
Килгәч Ходай каршына.
Бу дөньяда яшәгәндә
Нигезең булсын Иман,
Иманыңнан аерылсаң,
Ахирәттә бик яман.
Изгелек кыл җир йөзендә –
Савап булыр үзеңә,
Күңелеңнең Иман нуры
Балкып торыр йөзеңдә.
Дөньялыкта тыйнак бул син,
Яманлыктан ерак тор
Ялган сөйләп гайбәт сатма:
Гайбәт сату гонаһтыр.
Яман эш кылыр алдыннан
Уйла син азакларын,
Кот очарлык куркынычтыр
Ходайның газаплары.
Барча синең кылган эшең
Булсын тик изгелеккә.
Син бит монда кунак кына –
Кайтырсың мәңгелеккә.
Кылган гамәлеңне җыеп
Хисапларга салырлар,
Нинди гамәлләр кылдың, дип
Синнән сорау алырлар.

Иманымнан аерма дип.
Теләк телә көн саен,
Теләгән теләкләреңне
Кабул итсен Ходаем.

**Үңган апа Инзилә**

Инзилә апа коймак изә –
Шалтырый табаклары,
Алтын йөзекләр тезелгән –
Елтырый бармаклары.
    Капсаң телеңне йотарлык
    Пешергән коймаклары,
    Тел йотарлык коймак белән
    Сыйлый ул кунакларын.

Уйнап тора бармаклары –
Җыелган кунаклары,
Тигез итеп тезеп куйган
Майлаган коймакларын.

Кыстый-кыстый чәй эчерә
Тезелгән кунакларын,
Аның уңган бармакларын
Бизиләр балдаклары.

Уңган Инзилә апаның
Көймәгән коймаклары,
Аның килгән кунаклары
Мактыйлар коймакларын.
    Капсаң телеңне йотарлык
    Пешергән коймаклары,
    Тел йотарлык коймак белән
    Сыйлый ул кунакларын.

**Какы**

Авыр сугыш елларының
Заманалары каты:
Киндер күлмәк итәгемә
Җыеп тутырам какы.

Ачы какы, тәмле какы,
Булса да төбе каты,
Ачы сугыш елларында
Кыйммәт шул аның хакы.

Какыларны өзәмен дә
Итәгемә тезәмен,
Заманасы ачы булды –
Өзелә шул үзәгем.

Йөгерә-йөгерә басу буйлап
Җыеп ашадым какы,
Безнең авыр заманада
Булмады икмәк заты.

Юлыгызда очрасагыз
Татып карагыз какы,
Хәзер бит ул кыйммәт түгел –
Арзан бит аның хакы.

Ачы какы, тәмле какы,
Булса да төбе каты,
Ачы сугыш елларында
Кыйммәт шул аның хакы.

**Кыш Бабай**

Кыңгыраулы атлар җигеп
Безгә килә Кыш Бабай,
Күчтәнәчләр өмет итеп
Җыелган малай-шалай.

Тимер чанага утырып
Килеп житте Кыш Бабай,
Урап алган түгәрәккә
Биергә төште бабай.

Кыш Бабайга кул чабабыз:
---Бие, - дип, - давай-давай!
Шампан суын эчкән бабай
Әйттереп бии, малай.

Биеп йөрегән бабайга
Кычкыра бер шук малай:
—Биергә тебе хватит:
Күчтәнәч раздавай.

Мамык сакалын селкетеп
Биеп арый Кыш Бабай,
Күчтәнәчләр тутырылган
Капчыгын капшап карый.

Кыш Бабайны сырып ала
Берничә шаян малай,
Кулларын сузып сорыйлар:
–Подарки давай-давай!

Мыек астыннан елмаеп
Безгә карый Кыш Бабай,
Серле капчыгыннан алып
Бүләк тарата бабай.

Кыш Бабайны яратабыз:
Ни бирсә дә – шул ярый,
Тагын безгә Яңа Елны
Алып килсен Кыш Бабай.

**Кирпеч суга абыем**

Аягочта, каенлыкта,
Олы-Елга ярында
Ундүрт яшьлек үсмер малай –
Абыем кирпеч суга.
Кулларына көрәк тотып
Балчыкны чокып ала
Урынында мич сыярлык
Чокыры торып кала.
Кызыл балчыкны ала да
Манчып калыпка сала,
Кыска саплы тукмак белән
Кизәнеп берне суга.
Әйләндереп, ком сибә дә
Тагын бер тапкыр суга.
Җайлап кына калыпны алгач
Кирпече килеп чыга.
Көннең буе кирпеч суга –
Аның бит тамагы ач,
Кояш өскә күтәрелгәч
Алып барам төшке аш:
Шулпасында йөзеп йөри
Бер-ике, өч-дүрт умач.
Кирпеч сугып арып кайта
Кичен кояш баегач.
Шул елларны искә алам
Гомер еллары узгач,
Авылыма кайтып киләм
Шул елларны сагынгач,
Су буенда үзәкләрне
Өзеп сайрый сандугач.

Абыемны искә алып,
Яр буена карыймын,
Ярты гасыр үтсә дә мин
Шул чокырны таныймын,
Күз алларына китереп,
Бизәк ясап, тезеп куйган
Кирпечләрен саныймын.
Чокырына карыймын да,
Кул эзләрен таныймын,
Күзләремнән яшьләр тама –
Әйтерсең лә сабыймын.
Ул йөрегән сукмаклардан
Су буйларын буйлыймын,
Аның эзләренә басып
Тирән уйлар уйлыймын...

**Ирәняргыч**

Онытылмый бала чагым –
Күңелем тулы сагыш:
Алабута, ирәняргыч
Ашатты безне язмыш.

Ирәняргыч – тамак ялгыч –
Бала чактагы язмыш,
Чүп үләне белән утап
Ташлый күрмәгез ялгыш.

Өзеп алып беләгемә
Саламын ирәняргыч,
Үткәннәрне искә алып
Каламын уйда ялгыз.

Күз алдында тезелеп үсә
Яшел башаклы арыш,

Шул башаклар арасыннан
Җыямын иреняргыч.

Бала чакта ач-ялангач
Булмасын сезнең язмыш,
Безнең кебек балачакка
Дучар булмагыз ялгыш.
Иреняргыч – тамак ялгыч –
Бала чактагы язмыш,
Чүп үләне белән утап
Ташлый күрмәгез ялгыш.

## Төбәк тау

Биекләргә күтәрелгән
Аркабашның тау башы,
Еракларданкүренеп тора
Калган тауларның башы.
Аркабаш тау – биек тау,
Ул бит минем төбәк тау,
Чит илләрдә йөрәкләрне
Сызландыра торган тау,
Сөзәк кенә озын тау,
Минем туган изге тау,
Чит җирләрдә сагындырып
Үзәкләрне өзгән тау.

Аркабаш тау итәгеннән
Башлана авыл башы.
Шул авылның очларында
Туган нигезем ташы.

Аркабаш тавында калды
Күпләрнең нигез ташы,

Кире әйләнеп кайталмады
Аларның газиз башы.

Аркабаш тау буйларында
Калды җырлаган җырым,
Гомерем буена сакладым
Калган җырымның моңын.
    Аркабаш тау – биек тау,
    Ул бит минем төбәк тау,
    Чит илләрдә йөрәкләрне
    Сызландыра торган тау,
    Сөзәк кенә озын тау,
    Минем туган изге тау,
    Чит җирләрдә сагындырып
    Үзәкләрне өзгән тау.

## Билгесез ахыр

Җир йөзенә кеше мәңге килми –
Мин дә шулай бер көн үләрмен,
Дөньялыкта ризыгым беткәч
Кара гүргә килеп керермен.

Бәлки сезнең күргән төшегездә
Яныгызга кайтып килермен,
Бәлки җыеп оҗмах чәчкәләрен –
Чәчкәләргә сезне күмәрмен.

Бәлки кире кайтып бу дөньяга
Кулым сузып сәлам бирермен,
Бәлки сезне күреп – танымыйча
Арагызда уйнап йөрермен.

Җир йөзендә янып яшәгәнгә
Тәмугъларда бәлки янармын,

Бәлки иңеп биек һаваларга
Тамчы булып җиргә тамармын,
Яки күк йөзендә – мәңгелеккә
Йолдыз булып янып калырмын.

Ходай мине бәлки гафу итеп
Газаплардан үзе кичерер,
Оҗмахларда үскән гүр чәчкәсе итеп,
Сулар сибеп, назлап үстерер.

## Ялгыз кеше

Кайберәүләр артык ирек эзләп,
Шашып-ашыгып ясый ялгышлык,
Ә кемгәдер ирексезләп, качып
Көтмәгәндә килә ялгызлык.

Кайберәүләр чиксез артык кызып
Үзе теләп сайлый ялгызлык.
Андыйлары соңыннан үкенәләр,
Ясадык, дип юкка ялгышлык.

Кайсы юллар белән килсә дә, бер
Ялгызлыкның ачы язмышы,
Гомер буе килә юлдаш булып
Кара кайгы, сары сагышы.

Ялгызлык – кемгәдер иректер дә,
Алар белән булмый килешеп,
Йөрәкләрне талый моңлы сагыш –
Кемгә кирәк андый ирeклек.

Җиңел уйлап, алар ялгышалар:
Аңламыйлар йөрәк серләрен,

Ялгыз кеше ачмый тирән серен,
Юксынуда үткән көннәрен.

Кайберәүләр әйтә: –Күнеккән ул,
Ялгыз яшәп ялгыз тормышка...
Ышанмагыз, дуслар, берничек тә
Күнекмиләр андый язмышка.

Ышаныгыз минем сүзләремә,
Юл куймагыз андый карашка,
Ышаныгыз: озын еллар буе
Түзми йөрәк чиксез сагышка.

Дөрес, түзеп була ялгызлыкка
Өмет белән гомер иткәндә:
– Көтәм әле һаман берәүне, – дип, –
Булса әгәр кемне көтәргә.

## Авырлыкны җиңдек без

Авырлыкларны җиңдек без,
Биекләргә мендек без,
Сер бирмичә авырлыкка
Уйнап, җырлап көлдек без.

Еллар безне сынаса да,
Сабыр итеп түздек без,
Авырлыкның күлләрендә
Чума-чума йөздек без.

Авырлыкларны йөгәнләп
Кулыбызга алдык без,
Төшенкелеккә бирелми
Кеше булып калдык без.

Гомер атында чапканда
Артка калып килмәдек,
Дошманнар аяк чалса да,
Егылып җиңелмәдек,
Атлар булып җигелсәк тә,
Чыдадык – чигенмәдек.

Гомер юлын туры үттек –
Читләргә тайпылмадык,
Тормыш юлында югалып
Без адашып калмадык.

Туган-тума, дус-ишләрне
Оятка калдырмадык,
Кайгы утына салмадык,
Утларда яндырмадык.

Заманага туры килгән
Язмышка үкенмәдек,
Хыял утларында яндык,
Сүнмәдек – сүрелмәдек.

Кайгыларга каты тордык,
Булмаганны булдырдык,
Тоткан җирдән тимерләрне
Аяк тибеп сындырдык.

Атларда да чаптык без,
Мылтыктан да аттык без,
Авырлыкка җебеп төшми
Егет булып калдык без.

Уйламагыз мактана, дип,
Дөрес итеп аңлагыз,

Заманасы шундый булды,
Ялгыш уйда калмагыз.

**Гөлчәчәк**

Котлап синең бәйрәмеңне
Бүләк итәм мең чәчәк,
Гөлгә тиңләп исемеңне
Куштым сиңа Гөлчәчәк.
Аллы-гөлле Гөлчәчәгем,
Син бит үзең бер чәчәк,
Чәчкә аткан гөлләр кебек
Булсын синең киләчәк.

Синең бүген туган көнең,
Минем бәхетле көнем.
Син бит минем чәчкә аткан
Ялкынлы яшьлек гөлем.

Сокланып карап торамын –
Әйтерсең лә бер курчак,
Синең әле яшьлегеңнең
Гөле чәчәк аткан чак.

Язгы кояш нурын сипсен,
Якты булсын көннәрең,
Күңелеңдә чәчкә атсын,
Шиңмәсеннәр гөлләрең.
Аллы-гөлле Гөлчәчәгем,
Син бит үзең бер чәчәк,
Чәчкә аткан гөлләр кебек
Булсын синең киләчәк.

**Үзгәрде дөнья**

Дөньялар үзгәрде хәзер –
Урам буена кибет,
Сигаретларын кабызып
Кызлар эзли бай егет.

Бик тиз генә таба алмыйлар:
Бай егетләр бик сирәк,
Бай егеткә караганда
«Ярегетләр» күбрәк.

Урам тулы ярлы егет –
Йөриләр эчеп-тузып,
Һәрбер кибет почмагында
Торалар куллар сузып.

Ярлы егетләр юл баса
Барсаң базар юлыннан,
Тиен акча күреп калса,
Елап ала кулыңнан.

– Ике тәңкә җитми, – диеп
Яшен коя күзеннән,
Икмәккәме, шешәгәме –
Күренеп тора йөзеннән.

Кайберәүләр базар буйлап
Эзләп йөри «байсылу»,
Андыйлары читләп үтә
Басып торса «ярсылу».

Ярлы сылулар күбәйде –
Йөриләр матур атлап,

Сызылып таңнар атканчы
Торалар кафе саклап.

Ярлы сылу яулап ала
Туры килсә бай егет.
Кесәләрен тиз бушата,
Тормый ул эреп-җебеп.

Төшермәгез бәягезне,
Тормагыз кафе саклап,
Фәкыйрь кулларын сузмагыз,
Яшәгез намус саклап.

Урам буйлап шар сукмагыз,
Яшь егетләр, яшь кызлар,
Тырышыгыз – эш табыгыз –
Кулыгызда язмышлар.

## «Утырмакыз»

Ачы җилдә кышкы юлга
Кар буранын тутыра,
Күрше авылның җиткән кызы,
Кайтмас өчен сәбәп табып,
Утырмада утыра.

Кич караңгы төшү белән
Аулак өйгә сыптыра,
Күзен-башын күтәрмичә,
Күп сөйләшми тыйнак кына,
Чигү чигеп утыра.

Иртә торып суга бара
Кашын-күзен төзәтеп,

Чиләкләрен тутырып кайта
Яшь егетләрне күзәтеп,
Уңганлыгын күрсәтеп.

«Утырмакыз» суга йөри
Күтәреп чиләкләрен,
Су юлында егет күрсә,
Күз карашлары елмая,
Җилкенә йөрәккәе.

«Утырмакыз» утырмада
Кияү көтеп утыра,
Һәр көн саен суга барып,
Бизәк төшкән чиләгенә,
Чишмә суын тутыра.

Утырмада утырса да,
Утырган кыз утыра,
Утыз яшьләренә җитеп
Кияү эзләп табалмаса,
Акылына утыра.

**Алия**

Алсу йөзле Алия
Бакчада чәчкә җыя,
Үзе чәчкә булгангамы –
Аны чәчкәләр сөя.

Кечкенә кыз Алия
Зәңгәр күлмәген кия,
Күзе зәңгәр булгангамы –
Аны йолдызлар сөя.

Зәңгәр күзле Алия
Күптән тәпи йөгерә,
Һәр көн саен үсәм диеп
Күккә таба үрелә.

Анық күзе зәп-зәңгәр,
Үзе дә бит бик зәһәр,
Ул тагын да матурланыр –
Зурырак үссә әгәр.

Минем кызым үсәр әле
Зәңгәр күлмәкләр киеп,
-Картәти! – дип килер әле
Зәңгәр чәчкәләр җыеп,
Йөгреп килеп кочып алыр
Сандалиларын киеп.

**Тәүге сөю**

Истән чыкмый тәүге сөю,
Еллар үткәнен белми,
Яшьлегемнең тәүге кызы
Йөрәккә тынгы бирми.
Мин әле дә сине сөям,
Тәүге кызым Фәниям,
Тәүге мәхәббәт алдында
Тезләнеп башым иям.

Онытылмый яшьлектәге
Сөю утында көю,
Йөрәгемдә дөрләп янган
Ялкынлы тәүге сөю.

Искә төшкән минутларда
Әле дә янам- көям,
Гомеремнең тәүге кызын
Гомер буена сөям.
Мин әле дә сине сөям,
Тәүге кызым Фәниям,
Тәүге мәхәббәт алдында
Тезләнеп башым иям.

## Соңгы кырау

Килде язлар, үтте җәйләр,
Төште көзге кыраулар,
Үтеп китте яшьлегең дип,
Минем колак очларымда
Чыңлыйлар кыңгыраулар
Әй кыраулар, кыраулар,
Бирәм сезгә сораулар:
–Нигә миңа тидегез? – дип,
–Кайда калды яшьлегем? – дип
Чыңлыйлар кыңгыраулар.

Үтә гомер, ага еллар,
Чәчкә төшә кыраулар,
Гомер үтсен, чәч агарсын,
Тик күңелгә төшмәсеннәр
Көзге салкын кыраулар.

Җир йөзенә ап-ак булып
Төшә соңгы кыраулар.
Төшсә төшсен соңгы кырау:
–Язгы кырау сукмасын, – дип
Чыңлыйлар кыңгыраулар.

Әй кыраулар, кыраулар,
Бирәм сезгә сораулар:
-- Нигә миңа тидегез? – дип,
-- Кайда калды яшьлегем? – дип
Чыңлыйлар кыңгыраулар.

**Таңчулпан**

Бүген синең туган көнең,
Сөекле кызым минем,
Зәңгәр күктә якты янган
Чулпан йолдызым минем.
Синең бүген зур бәйрәмең,
Бу дөньяга килгән көн,
Исемеңне күк йөзенә
Йолдыз язып куйган көн.

Исемеңне таң атканчы
Уйлап яттым йокысыз,
Таң алдыннан күккә карап
Бүләк иттем бер йолдыз.

Сине котлап якты йолдыз
Елмая күк йөзендә,
Таң алдыннан сине назлап
Нурын сибә йөзеңә.

Котлы булсын туган көнең,
Күркәм булсын табының,
Телим сиңа җир йөзендә
Үз йолдызың табуын.
Синең бүген зур бәйрәмең,
Бу дөньяга килгән көн,
Исемеңне күк йөзенә
Йолдыз язып куйган көн.

## «Кырыгың»

**Мәрхүм җизнәмнең кырыгына багышланган.**

Бүген, җизни, синең кырык көнең,
Соңгы туең, моңсу бәйрәмең,
Җиңел туфрак теләп хәер бирәм,
Бүләк итмим чәчкә бәйләмен.

Җыелдык без бу табынга,
Сине сагынып искә алырга,
Иман чиккән түбәтәйләр киеп
Коръән сүрәләрен тыңларга.

Җыелганнар барча туганнарың,
Тезелгәннәр синең газиз балалар,
Гомер юлларыңны искә алабыз,
Йөрәкләрдә сызлый яралар.

Бер ни эшләп булмый – бу дөньяга
Ходай безне шулай яраткан,
Барчабызның маңгаена язып,
Тәкъдир язмышларын тараткан.

Ходай каршысына килеп баскач
Нурлы булсын синең йөзләрең,
Гамәл дәфтәреңне алып үлчәгәндә
Күбрәк тартсын изге эшләрең.

Ходай сиңа үзе ярдәм итсен
Ахрызаман көне җиткәндә,
Кылычтан да үткен, кылдан нечкә
Сират күперләрен үткәндә.

Изге бурычларын үтәп – балаларың
Җирләделәр туган җиреңә,

Ахирәткә кадәр тыныч йокла –
Йоклыйсың син туган иленңдә.

Онытмаслар сине туганнарың,
Кабереңә сукмак «тапарлар»,
Баш очыңа куйган таш алдына
Болын чәчкәләрен салырлар.

## Дамирга

Әнкәң сиңа Дамир, диеп
Яратып исем кушкан,
Тәүге улым – күз нурым, дип
Кулында кысып кочкан.

Батыр булып үссен, диеп
Күкрәк сөтен имезгән,
Туган илгә хезмәт итсен,
Хезмәтне сөйсен, дигән.

Син авырган вакытларда
Янып-кайгырып көйгән,
Төн йокыларын йокламый
Кулында тирбәтеп йөргән.

Сабый чакларыңда сиңа
Матур көйләр көйләгән,
Балам бәхетле булсын дип
Ак теләкләр теләгән.

Әнкәйләрнең изге була
Теләгән теләкләре,
Үсеп җитеп, терәк булып
Кабул ит теләкләрен.

## Туган көн

Туган көн – ул иң якты көн,
Якты дөнья күргән көн,
Ак бәхетләргә төренеп
Бәйрәм итә торган көн.
  Әй туган көн, туган көн --
  Ул бит синең яңа көн,
  Гомереңнең яңа елын
  Каршы чыгып алган көн.
Туган көн – ул якты кояш
Нурын сибә торган көн,
Күңелләрдә якты хыял
Чәчкә ата торган көн.

Һәр көн шулай бүгенгедәй
Бәхетең юлдаш булсын,
Йөзләреңдә якты кояш
Нурлары уйнап торсын.

Гомер үтсен, еллар узсын,
Туган көн килеп торсын,
Ел саен әйләнеп килгән
Бәйрәмең котлы булсын.
  Әй туган көн, туган көн –
  Ул бит синең яңа көн,
  Гомереңнең яңа елын
  Каршы чыгып алган көн.

## Сабак

Яшең китсә сиксәнгә
Акча тотма кесәңдә,
Кәфенлектә кесә булмас
Алып китәм дисәң дә.

Яшең китсә сиксәнгә,
Акча керсә кесәңә,
Хәерен бир, намазлык ал,
Үрелмә син шешәгә.

Яшең җитсә сиксәнгә
Карама яшь бичәгә,
Җайлап-майлап, ике куллап
Керер синең кесәңә.

Әгәр җитеп сиксәнгә
Өйләнсәң яшь бичәгә –
Акча җыйма кесәңә,
Бир артыгын син балаңа,
Ышанма яшь бичәңә.
Яшең китсә сиксәнгә
Ышанма яшь ирләргә,
Байлыгыңны тартып алып
Салыр кара җирләргә.

Байлыгың бир үз балаңа,
Булса яшең сиксәндә,
Кәфенлектә кесә булмый
Ничекләр теләсәң дә.
Сабак итеп кабатлыймын –
Җыйма акча сиксәндә.

**Мәхәббәтне саклагыз**

Гомер буе яшьлектәге
Мәхәббәтне саклагыз:
Мәхәббәт – ул мәңге яшьлек,
Аннан «колак какмагыз».

Юкка үпкәләгән булып
Дөньягызны бозмагыз,
Ашыкмагыз, үтеп китәр,
Бик тиз генә кызмагыз.
Кызган чакта су кабыгыз.
Чамасыннан узмагыз,
Тоткан җирдән уйламыйча
Чыбыкны сындырмагыз.
Гомер юлларын үткәндә
Җил булып сызгырмагыз,
Тормыш йөгенә җигелгәч
Кинәт кенә артык дулап,
Тәртәне сындырмагыз.
Нәфсегә хуҗа булыгыз,
Куймагыз аңа ирек,
Тормыш атында чапканда
Булмасын тәртә–зирек.
Яшьли сөйгән ярыгызны
Ятларга калдырмагыз,
Киткән юлыгызда калган
Күперне яндырмагыз.
Үз ярыгызны кочыгыз,
Башкага алыштырмагыз,
Гомер буе сүрелмәсен
Мәхәббәт учагыгыз.

## Яңавылым

Яңавылны күрер өчен
Килсә безгә түрәләр
Искитәрлек гүзәллеккә
Хәйран калып китәләр.

Әх, Яңавыл, Яңавыл,
Авыл түгел – кала ул,
Читтән килгән кунакларны
Кочагына ала ул,
Кунак итеп, саубуллашып
Озатып та кала ул.

Җиң сызганып басуларда
Эшли игенчеләре,
Яңавылга ямь өстиләр
Аның төзүчеләре.
Әх, Яңавыл, Яңавыл,
Авыл түгел – кала ул,
Ямьле матур урамнарга
Биек йортлар сала ул,
Заманадан калышмыйча
Алга таба бара ул.

Бик сагынып якташлары
Кайта сабантуена,
Җәй көнендә ял итәргә
Буә елга буенда.
Әх, Яңавыл, Яңавыл,
Авыл түгел – кала ул,
Бик сагынган якташларын
Кочагына ала ул,
Читтән күчеп кайтканнарны
Куенына ала ул.

Яратамын Яңавылны,
Яратам кешеләрен,
Җәй көнендә урамнарда
Чәчкә аткан гөлләрен.

Әх, Яңавыл, Яңавыл,
Авыл түгел – кала ул,
Яңавылны еракларга
Ташлап китү – кая ул,
Минем өчен бу дөньяда
Иң кадерле – Яңавыл.

## Гомер мизгеле

Кеше гомере «ә» дигәнче
Үтеп китә тиз генә,
Бу дөньяга килеп кереп
Тик чыгып китү генә.

Җир йөзендә яши кеше –
Ниндидер мизгел генә,
Бу гомернең мизгеллеген
Аңламыйбыз тиз генә.
Бер ишектән килеп кереп
Дөньяны күрү генә,
Икенче ишекне ачып
Тик чыгып китү генә.

Ике ишекнең арасы
Ике адым җир генә,
Кеше җир астына китә –
Кала искән җил генә.

Ишек артыннан сузылган
Сират күпере генә,
Ул күперне саклап тора,
Бер Ходай – үзе генә.

Сират күпере дигәне
Бер сузылган кыл гына,
Шул кыл аша үтәр өчен
Гомереңнең мизгелендә
Кыл син изгелек кенә.

Бәлки җир йөзе үзе дә
Ниндидер бер көзгедер,
Дөньялыкның дингезендә
Бер кабынган мизгелдер.

**Бары да сигез номерлы**

Хатын-кыз бәйрәме җитте –
Аның номеры сигез,
Салып аракы эчәләр
Ирләр белән бер тигез.

Сигезенче Март көнендә –
Барына да унсигез,
Бит очлары янып тора,
Иреннәре гөлҗимеш,
Егып ирләрне үбәләр,
Туры килсә дә чирмеш.

Урамда йөри бичәләр –
Бары да сигез номерлы,
Берсе шешә борыныннан
Эчеп тора – убырлы.

Ике кыз керде кибеткә,
Чыгалар бер-бер артлы,
Ике сигезең уналты –
Кулларында бер ярты.

Килеп чыкты ике хатын
Сигезле номер асып,
Нормаларын тутырганнар –
Киттеләр кыек басып.

Эчеп алган хатын-кызга
Бөтен дөнья бер тигез,
Эчеп бөлгенгә төшсә дә –
Тубыктан аңа диңгез.

Барысы да исерекләр,
Ирләре дә «егетләр»,
Бу бозылган хатыннарны
Кемнәр хәзер үгетләр.

Заманабыз нык үзгәрде –
Өзелә бит өметләр,
Карап аптырашка калам:
–Эх, егетләр, егетләр.

Безнең дөнья болай барса
Арбаны кем дегетләр?
Үзебезне кулга алсак
Булыр безнең өметләр.

## «Нине» нитәргә кирәк

«Нине» кыстырмыйча гына
Сөйләгән кеше сирәк,
Ни сөйләргә теләгәнен
Көтеп торып – авызыннан
«Сөйрәп» алырга кирәк.
Алай итәргә кирәк,
«Нине» нитәргә кирәк,

Ни әйтергә уйлаганны
Күпме котәргә кирәк.
Болай итәргә кирәк,
«Нине» нитәргә кирәк,
«Нисез» генә матур итеп
Сөйли белергә кирәк.

Аның телен аңлар өчен
Зирәк булырга кирәк,
Тукай язган татар телен
Кирәкмәгән сүзләр белән
Нигә чүпләргә кирәк?

Әйтер сүзеңне әйтергә
Телне борырга кирәк,
Ни әйтергә теләгәнне
Алдан белергә кирәк.
Болай итәргә кирәк,
«Нине» нитәргә кирәк,
Мул әдәби тел байлыгын
Саклый белергә кирәк.
Алай итәргә кирәк,
Болай итәргә кирәк,
«Нине» кушып сөйләүчеләр
Булсыннар иде сирәк.

**Кемнедер көтә йөрәк**

Тагын да бер кышым үтә,
Язларым килеп җитә,
Назга сагышлы йөрәгем
Һаман кемнедер көтә.

Моңсуланып язмышыма
Ялгыз көннәрем үтә,
Көтәргә калган йөрәгем
Һаман көтә дә көтә.

Килер кешем булмаса да
Кемнедер өмет итә,
Көткән юлларыма карап
Гомер елларым үтә.

Йөрәгемнең һәр яртысы
Янып үз ярын көтә,
Янып үткән һәрбер көнем
Гомер йомгагын сүтә.

Янырга калган йөрәгем
Яна ул иртә-кичтә,
Гомер буе көйрәп яна,
Сүрелми икән һич тә.

Гомер елгаларым ага –
Ярларында ялгызым,
Шул елганың аръягында
Калды минем язмышым.
Әллә язмыш, әллә ялгыш,
Әллә йөрәк сагышым.

## Яр буенда учак яна

Син киләсе юлдан күзләремне алмый
Сине көттем – ләкин килмәдең,
Яр буенда янган очкын учагымның
Очкыннарын әллә күрмәдең?

Төн карасын ярып, чаткылары очып,
Таңга чаклы янды учагым,
Яңа язлар көтеп, сине өмет итеп,
– Килерсең, – дип, назга сусадым.

Күптән сүнде учак, калды күңел бушап,
Якыная гомер көзләре,
Ә йөрәктә һаман яна соңгы учак –
Ялкынланып көйри кузлары.

Су буенда чатнап кичке учак яна,
Хәтерләтеп яшьлек кичләрен,
Шул учакның чаткылары булып
Биекләргә оча хисләрем.

**Кайтам әле**

Кайтам әле авылыма –
Минем туган якларым,
Булмаса да сагынып көткән
Якын туган-затларым.

Чакыралар шул якларга
Минем бала чакларым,
Җәйге кичтә учак ягып
Атлар көткән чакларым.

Кайтам әле булмаса да
Менеп чапкан атларым,
Алмасам да авылымның
Язган сәлам хатларын.

Кайтам әле, күрәм әле –
Минем гүзәл якларым,

Үзәннәрдә шау-гөр килеп
Уйнап үскән чакларым.

Чит илләрдә йөресәм дә –
Күңелемдә сакладым,
Туган якның гүзәллеген
Бер җирдә дә тапмадым.

## Әтием истәлеге

**Әтиемнең истәлеген**
**Сезгә язам мирас итеп –**
**Укыгыз эчтәлеген.**

Сугыш чыккан көннәрендә
Әти Аскынга бара,
Алда булган сугышларда
Яраланып кайткангамы –
Сугышка бармый кала.
Әллә Ходай кушкангамы –
Өйдә бит алты бала,
Берсеннән берсе «мала»:
Тормыш иткән иптәшеннән
Ялгызы торып кала.
Ач-ялангач алты бала –
Утырып уйлап кара.
Шул алты баласын ияртеп
Торып кала бичара.
Өстәвенә илебездә
Кан коеш сугыш бара –
Бу кайгыдан араларга
Юк бит бер нинди чара.
Алтынчысы – кул баласы,
Алты айлык булып кала,

Бу бит аның йөрәгендә
Мәңгелек калган яра.
    Һәр көн иртән эшкә бара
    Колхозга печән чаба,
    Сабан сөрә, иген чәчә,
    Өсте-башы кап-кара,
    Попробуй бармый кара –
    Илдә бит сугыш бара.
Язгы чәчү эше беткәч
Колхоз атларын көтә,
Иген җиткәч – төнгелеккә
Басу сакларга китә.
Тимерлектә арба ясый,
Тутык тырмалар сүтә,
Бозык җирләрен төзәтеп
Аларны рәткә кертә.
Эштән кайта, утын яра.
Кертеп учагын яга,
Мал эчерә, печән сала,
Дөньясы шулай бара –
Түгел бит авыл кала.
Кыш көнендә атлар җигеп
Урман эшенә китә –
Өсте өзелеп бетә,
Өйдә калган балалары
Аны тилмереп көтә.
Хөкүмәтнең кырык төрле
Налогы «душить» итә,
Шул налогны түләр өчен
Мич чыгарырга китә.
Мич чыгарган акчаларын
Сельсовет алып китә.

Үзәннәрдә шау-гөр килеп
Уйнап үскән чакларым.

Чит илләрдә йөресәм дә –
Күңелемдә сакладым,
Туган якның гүзәллеген
Бер җирдә дә тапмадым.

## Әтием истәлеге

**Әтиемнең истәлеген**
**Сезгә язам мирас итеп –**
**Укыгыз әчтәлеген.**

Сугыш чыккан көннәрендә
Әти Аскынга бара,
Алда булган сугышларда
Яраланып кайткангамы –
Сугышка бармый кала.
Әллә Ходай кушкангамы –
Өйдә бит алты бала,
Берсеннән берсе «мала»:
Тормыш иткән иптәшеннән
Ялгызы торып кала.
Ач-ялангач алты бала –
Утырып уйлап кара.
Шул алты баласын ияртеп
Торып кала бичара.
Өстәвенә илебездә
Кан коеш сугыш бара –
Бу кайгыдан араларга
Юк бит бер нинди чара.
Алтынчысы – кул баласы,
Алты айлык булып кала,

Бу бит аның йөрәгендә
Мәңгелек калган яра.
Һәр көн иртән эшкә бара
Колхозга печән чаба,
Сабан сөрә, иген чәчә,
Өсте-башы кап-кара,
Попробуй бармый кара –
Илдә бит сугыш бара.
Язгы чәчү эше беткәч
Колхоз атларын көтә,
Иген җиткәч – төнгелеккә
Басу сакларга китә.
Тимерлектә арба ясый,
Тутык тырмалар сүтә,
Бозык җирләрен төзәтеп
Аларны рәткә кертә.
Эштән кайта, утын яра.
Кертеп учагын яга,
Мал эчерә, печән сала,
Дөньясы шулай бара –
Түгел бит авыл кала.
Кыш көнендә атлар җигеп
Урман эшенә китә –
Өсте өзелеп бетә,
Өйдә калган балалары
Аны тилмереп көтә.
Хөкүмәтнең кырык төрле
Налогы «душить» итә,
Шул налогны түләр өчен
Мич чыгарырга китә.
Мич чыгарган акчаларын
Сельсовет алып китә.

Ул сельсовет дигәненең
Бар җиргә кулы җитә:
Тумаган сыер бозавын
Алдан ук язып китә.
Сөтен дә алып китә,
Маен да алып китә,
Тумаган сарык бәрәнен
Шулай ук язып китә.
Суйган кәҗә тиресен дә:
–Китер! – дип килеп җитә.
Хәтта тавык тизәген дә
Сыпырып җыеп китә.
Йомыркасын, йонын да,
Күмерен һәм көлен дә.
Әти, мескен, хөкүмәткә
Илтеп сдавать итә:
Попробуй бирми кара –
Башың Себергә китә.
Күпме таласа да тулмый
Хөкүмәтнең нормасы,
Ачу килгәч язам инде –
Арт ягымның формасы.
Күп тә үтми олы улын,
Бердәнбер таянычын
Хәрби хезмәткә алдылар –
Калмады ярдәмчесе.
Унҗиде яшь тулмас борын
Китте илнең чигенә
Шинель киеп, мылтык асып,
Каеш буды биленә.
Ил чигендә сакчы булып
Озын җиде ел буена

Хезмәт итте иленә.
Әти мескен ил чигеннән
Тилмереп хатлар көтә,
– Балам әйләнеп кайтыр, – дип,
Ышанып өмет итә.
Торып калды иң олысы
Унөч яшьлек кыз бала,
Аңардан соң тезелгәннәр
Тагын да бит дүрт бала,
Хөкүмәт безне талагач
Ашарга нәрсә кала?
Оннан пешергән икмәкне
Ашарга тилмерәбез,
Имән каерысы кушылган
Алабута икмәге бар –
Без шуңа күнегәбез.
Язга таба ул да бетә,
Берни калмый кабарга,
Амбар астына керәбез
Идән ярыгыннан төшкән
Арыш чүпләп ашарга.
Базга салган бәрәңгебез
Кала чәчәрлек кенә,
Шушы дәрәҗәгә җиткәч
Ничек яшәргә менә?
Өй баскычын менгән чакта
Калтырый тезләребез,
Утын күтәреп кергәндә
Бөгелә биләгебез –
Өзелә үзәгебез.
Үлән чыкканын көтәбез,
Ач тамакны басарга,

Кычыткан башларын җыеп
Аш пешереп ашарга.
Ул ачлыкка интеккәнне
Кәгазь җитми язарга,
Әле монысы калып торсын –
Башка сүз бар язарга.
Унөч яшьтә калган кызы
Үсеп буена җитә,
Дөнья көткән таянычы
Кияүгә чыгып китә.
Ул кияүгә китү белән
Өйдә безнең рәт китә:
Киндер суккан күлмәгебез
Тузып тишелеп бетә.
Алай да болганабыз –
Болай да болганабыз,
–Әни калдырып китте, – дип
Әнкәйне сагынабыз,
Язмышка зарланабыз.
Көн артыннан көн үтә,
Көзләр дә килеп җитә,
Кече апа Гөлфидәкәй
Әнкәемне сагынудан
Тиз генә үлеп китә.
Һәр көн саен ике абый
Мәктәпкә чыгып китә,
Әти мескен балта алып
Урманга кереп китә,
Кайвакытта ул мине дә
Үзе белән ияртә.
Тау астында ага чишмә,
Өстендә – үсә юкә,

Шомаларын сайлап кына
Әти юкәләр кисә.
Өч юкәне бергә бәйләп
Ул миңа да күтәртә,
Ярый әле юкәләр бар –
Алар нык ярдәм итә.
Алып кайтып юкәләрне
Ишек төбенә тезәм,
Әтиемә булышам дип
Шатлык күлендә йөзәм.
Әти аны бишкә ярып
Читләрен кырлап тезә,
Шул юкәне сыдырып алып
Чабата ясый безгә.
Аны ясау ансат түгел:
Ул зур профессия –
Кайберәүләр генә ясый,
Киюен – бары да кия.
Шөшле ялтырап тора,
Куллары уйнап тора.
Аның уңган кулларына
Өйрәнеп карап торам.
Ул ясаган чабаталар
Елмаеп көлеп тора.
Ясады ул төрлесеннән:
Кызларга – сырлы башлы,
Урыс чабатасы булса –
Анысы кыек башлы,
Безнең кебек малайларга
Сыры юк – шома башлы.
Өйрәтте ул матур итеп
Чабаталар ясарга,

Аның калды васыяте --
Безгә эшләп ашарга.
Сакладык без васыятен –
Җиң сызганып эшләдек,
Хәрам ашын ашамадык,
Кешенекенә тимәдек,
Байлык юк дип көймәдек.

**Икенче бүлек**
Әни үлгәч биш ел үтә –
Интегеп дөнья көтә,
Аның уртанчы малае
Яше җитми – үсмер егет
Ташкентка чыгып китә.
Яшен бер елга арттырып
Алдап шахтага төшә,
Җир астында үсмер егет
Тезләнеп күмер кисә,
Акчасы яхшы төшә,
Яхшы төшкән акчасыннан
Безгә дә өлеш төшә.
Акча җыеп отпускага
Ел саен кайтып китә,
Бигрәк тә безнең әти
Аны өзелеп көтә,
Абый кайтып керү белән
Өйләр ямьләнеп китә.
Барыбыз да шатланабыз,
Кочаклыйбыз, үбәбез,
Сандык чаклы чемоданын
Ачканын без көтәбез.
Ят җимешләр алып кайта,

Аякка – киез ката,
Безнең түбә күккә тия,
Дисәң дә булмас хата.
Чалбар да алып кайта,
Күлмәк тә алып кайта,
Әтиемнең налогын да
Әзерәк йомшата.
Лыстыр киемне бәрәбез –
Алар почмакта ята.
Шатланабыз, сөенәбез,
Яңадан киенәбез,
Көзге каршысына басып
Тагын бер сөенәбез.
Бер ай буе өебездә
Кунак булып ял итә,
Егет кеше – күрше авылга
Кызлар күзләргә китә,
Отпускасы бетүенә
Тагын Ташкентка китә.
Абый китеп күп тә үтми
Без яңадан бөләбез,
Әтиемнең эшләгәнен
Хөкүмәткә бирәбез,
Күп михнәтләр күрәбез.
Кызарып кояш чыкканчы
Әти чүкенә башлый,
Көне-төне эшли әти,
Колхозга чана ясый.
Мичкә ягып, мич кыздырып
Аның табанын бөгә,
Көянтәсен, дугасын,
Чаңгы башын да бөгә,

Тәгәрмәчнең түгәрәген –
Анысын да ул бөгә.
Көне-төне бөгелгәнгә
Колхоз трудодня бирә.
Ул трудодня дигәннәре –
Бер әлеп тә, бер таяк,
Ул таякка берни тими,
Чөнки хөкүмәт карак.
Хөкүмәтнең ояты юк –
Талый күзеңә карап.
Урам буйлап күмер җыйган
Коробларны ул үрә,
Су буенда тал чыбыгын
Кисеп кәрзиннәр үрә,
Председатель тарантасын –
Каен чыбыктан үрә.
Әтиемнең кулы алтын –
Җитмеш төрле эш белә,
Каен тузларын куптарып
Күнәк тә ясый белә.
Йөгәнен дә ул үрә,
Шлиясен дә үрә,
Хәтта атларның камытын
Колхозга эшләп бирә.

Кыш буена бау ишәбез –
Әтиемә булышам,
Мин, әлбәттә, бәләкәй шул,
Олылардан калышам.
Ярый әле үсә юкә,
Ул булмаса нишләр идек –
Дөньяны тота юкә.
Дилбегәләр ишәбез,

Аркалык та ишәбез,
Тәртә бавын, камыт бавын,
Тезгенен дә ишәбез.
Беләк юанлык арканны,
Әлбәттә, эти ишә,
Безнең хәләл көчебезне
Хөкүмәт учлап «ишә».
Хәтерләмим этиемнең
Чыбыркылар ишкәнен,
Кулларына камчы тотып
Атларда йөрегәнен.
Аның кулларында булды
Орчык буе бер чыбык,
Йөген тарткан малкаена
Сукмады чыбык сузып.
Изге булды күңелләре,
Тормыш авыр булса да,
Бик сораган кешеләргә
Пима төпләрен сала.
Сумалалы җебен тартып
Кулы була кап-кара.
Ярты авыл кешесенең
Өреп чәчләрен ала,
Кылган изгелеге өчен
Меңнәрчә рәхмәт ала.
Ясады ул кешеләргә
Иләген-чиләген дә,
Гөбесен дә төпләп бирде
Мохтаҗлы кешеләргә.
Бер бөртек тә кер булмады
Иманлы йөрәгендә.
Гарәп телендә язылган

Коръәнне укый белә,
Изге коръән эчтәлеген
Тәфсилләп тезеп бирә,
Икенде-ахшам намазларын
Калдырмый укып килә.
Намазлыкка менеп баскач
Мин дә янына киләм,
Ничә тапкыр иелсә дә,
Мин дә шулай иеләм.
Укыйбыз изге намазны,
Икебез дә бергәләп,
Мин кечкенә, ә ул миннән
Ике аршин биегрәк.
Йолдыз төшкән намазлыкта
Коръән көен көйлибез,
Дини бәйрәмнәре җитсә
Әти белән шыпырт кына
Гаетләргә йөрибез.
Анын уку китаплары
Барысы да гарәпчә,
Бармак бөгеп: –Әлпи, ти, си, –
Диеп саный кайчакта.
Хатлар яза гарәпчә,
Хатлар килә гарәпчә,
Җиде еллык мәдрәсәдә
Белем алган үзенчә,
Күп догалар яттан белә
Укымышы да оста,
Иман белән гамәл кыла
Бик әдәпле тормышта.
Ачлы-туклы яшәсә дә
Уразасын да тота.

– Хәрам аш ашамагыз, – дип
Тәмуг белән куркыта,
Кылган изгелеге белән
Тирә – юньдә дан тота.

## Өченче бүлек

Ел артыннан ел үтә,
Сугыш еллары бетә,
Безнең әти эчтән генә
Хөкүмәтнең тулалмаган
Төпсез капчыгын «сүтә».
Аны да болай итә,
Моны да болай итә,
Еллар буе налог түләп
Бөтенләй бөлеп бетә.
Якты тормыш килерме, дип
Өмет иткән киләчәккә
Бөтен өмете бетә.
Аптырагач язга таба
Сыерына чана җигеп,
Җиде төннең уртасында
Авылдан чыгып китә.
Әтиемнең дөнья малы
Чанага сыеп бетә,
Алда аны өр-яңадан
Башланмаган эш көтә.
Сауган сыерын җитәкләп
Агарзяга юл тота,
Аның барган төнге юлын
Ай яктысы яктырта.
Агарзя дигән поселок
Тирә-якта дан тота,

Анын ботен урамнарын
Лампочкалар яктырта.
Стансада һава ярып
Паровозлар кычкырта.
Анда яши колхозлардан
Качып килгән кешеләр,
Ялкаулыкны белми торган –
Барда уңган эшчеләр.
Барысы да дәртле халык,
Җырлап урман кисәләр,
Мич башында бал ачытып,
Бәйрәмнәрдә җыелышып,
Утырып бал эчәләр.
Иртәгесен сөйләшәләр –
Кемнең балы катырак,
Кемнең ите симезрәк,
Кемнең аты яхшырак.
Һәр йорт саен ат тоталар,
Читтән алып кайталар,
Көз көнендә суеп ашап
Калган итен саталар.
Менә шулай яши алар
Иркен, мул тормыш белән,
Әтием дә күчеп килде
Ышаныч, өмет белән.

Әтиемә өй төзергә
Урман бүлеп бирделәр.
–Агачларын кисеп алып
Өй төзерсең, – диделәр.
Агачларны кисәбез дә
Ботагын яндырабыз,
Тамырына күсәк тыгып

Төпләрен каерабыз.
Кара урман үскән җирне
Яланга калдырабыз,
Шулай итеп бакча ясап
Өй нигезен корабыз.
Күл буенда өебез бар –
Әле шунда торабыз.
Күлебездән сулар ташып
Мунча ягып керәбез,
Өебез зур булмаса да,
Гаилә ишле булса да,
Без аңарга сыябыз.
Кар эрегәч өебезне
Язгы ташкын су баса,
Һәр ел саен куласадай
Әйләнеп килеп баса.
Әти безгә бик кушылмый:
Аның эшләре башка,
– Гомер буе эшләргә, – дип,
Язып куелган ташка.
Агарзяга килү белән
Биленә аса балта,
Почмак чабып бура бурый –
Андый эш кыйммәт хакта.
Кеше кебек көн күрергә
Кирәк бит аңа акча.
Һәр ел саен әти эшләп
Ат сатып алып кайта.
Хәзер тормыш йөгебезнең
Бер өлешен ат тарта.
Кышкылыкка аны суеп
Итен безгә ашата.

Барча булган балаларын
Җыйды канат астына,
Аерым өйдә торганнарын
Ала кунак ашына.
Өйгә агач кисәргә, дип
Исәбе бар башында,
Нигез салган яңа җиргә
Өй салырга ашыга.
Дөнья көткән атыбызны
Чанасына җигәбез,
Балта, пычкы, көрәк салып,
Урманга ашыгабыз.
Әти белән делянкада
Өйгә агач кисәбез,
Учак ягып, кар эретеп
Аның суын эчәбез.
Ашарга да коры-сары –
Анысына түзәбез.
Чыршыларның төзен сайлап
Тирән карда йөзәбез дә,
Берәм-берәм егып салып,
Бүрәнәгә кисәбез.
Җиккән ат белән тарттырып,
Олы юлга алып чыгып,
Штабельгә тезәбез.
Абыйларым җыелышып
Йөк төяргә баралар,
Штабельдән агачларны,
Багор белән тәгәрәтеп,
Машинага салалар.
Үгез төшкән зур машина
Йөкне үкереп тарта,

Паровоздан чыккан кебек
Төтене кала артта,
Безнең кискән бүрәнәләр
Йөккә төялеп кайта.
Абыйларым йөкне чишеп
Бик тиз генә бушата,
Өйгә диеп кискән агач
Безнең урамда ята.
Әти белән кода бабай
Өй бурасын бурыйлар,
Сүз куешып кул алмаштан
Аларга да бурыйлар,
Эшне җәйгә бетерәләр,
Бик озакка сузмыйлар.
Җәй буена өй төзибез –
Булышалар абыйлар,
Син бит төпчек баласы дип,
Бу өй сиңа каласы, дип,
Син күбрәк эшлә, диеп
Миңа бармак яныйлар.
Мин, әлбәттә, тырышамын,
Әтигә булышамын,
Уч төпләрем кабарганчы
Бүрәнәне ешамын.
Ундүрт яшьләрдә булсам да
Мин алардан көчлерәк,
Бүрәнәне күтәрергә
Аңа бит зур көч кирәк.
Эшкә тотыныр алдыннан
Кулга бияләй киям,
Бүрәнә башыннан тотып
Күтәреп алып чөям.

Менә шулай өй төзибез –
Уен-көлке бик сирәк,
Бүрәнәнең юан башы
Миңа төшә күберәк.
Түбә ябарга кирәк –
Барысы да тизерәк,
Кар яуганчы мич чыгарып
Өйгә керергә кирәк,
Бер абыем кәләш алды,
Әле торган өебезне
Аңа бирергә кирәк.
Ашыгабыз, тырышабыз,
Бөтен көчне бирәбез,
Кышкылыкка мичне ягып
Өйгә килеп керәбез.

Дөнья көткән атыбызны
Тагын егып суябыз,
Бакча тулы көзге байлык –
Анысын да җыябыз,
Өйләнмәгән абыем бар –
Килен дә алып куябыз.
Чаршау тартып өебезне
Бүлмәләргә бүләбез,
Кемгә кайда йокларга, дип
Бүлмәләрне бүләбез.
Әти белән үги әни –
Алар түрнең башында,
Абый белән минем җиңги –
Йоклый кухня ягында,
Асларына түшәк җәеп
Алар юрган ябына.

Минем өчен урын калды

Ишек төбе янында,
Асларыма тире җәеп
Иске шинель ябынам,
Зарланмыймын язмышыма –
Шул чакларны сагынам.
Яз җитүгә безнең әти
Балта эшенә китә,
Халык теле андый эшне –
Халтуркага дип әйтә,
Ә мин аны баштан үткәч
Бик авыр эш дип әйтәм.
Җәйгелеккә ул мине дә
Шул эшкә алып китә,
Үзе белгән бөтен эшкә
Сабыр гына өйрәтә,
Җитмеш төрле һөнәрен дә
Миңа эшләп күрсәтә.
Бозып эшләгән эшемне
Бармак төртеп күрсәтә,
–Эшләгәнең көлеп торсын, –
Диеп мине кисәтә.
Карышмыймын әтиемә,
Яңадан сүтеп корам,
Аның эшләренә карап
Әти кебек остарам.
Төзәтеп әйткән сүзләрен
Күңелгә салып барам,
Аның биргән киңәшләрен
Гомрем буе кулланам.
Абыйларым барысы да
Тир түгеп урман кисә,
Мактанырлык булмаса да,

Бераз акчасы төшә,
Барысы да гаилә корып
Тырышып дөнья көтә.
Бергә торган абыемның
Гаиләсе артып бара,
Әти күршедән өй алып
Аны башка чыгара,
Өч ел буе тату тордык –
Җил кермәде арага.
Хәзер инде өебездә
Өчәү генә калабыз,
Тормышыбыз иркенәйде –
Матур гына торабыз,
Киләчәккә исәп тотып
Икәү юллар сызабыз.
Кышкы карлар төшү белән,
Юлсыз җирдән юл ярып,
Хезмәт иткән атыбызга
Китәбез чана тагып.
Киң канатлы чанабызга
Ташыйбыз утын салып,
Җәяүләп чана артыннан
Кайтабыз икәү арып.
Алып кайткан утыннарны
Өябез кисеп, ярып,
Кышның буе мичебезгә
Яшибез утын ягып.
Менә шулай яши торгач
Мин үсеп буйга җитәм,
Унҗиде яшь тулмас борын
Урман эшенә китәм,
Акча эшләп өс киеме

Алырга өмет итәм.
Һәр көн барып урман кисәм,
Авыр булса да түзәм,
Бу озакка булмаганын
Күңелем белән сизәм.
Еллар буе кисә-кисә
Урман әзәеп бара,
Безнең арттан тезелешеп
Агач төпләре кала,
Урман бетсә, бөтен халык
«Төпкә утырып» кала.
Гөрләп торган Агарзядан
Халык таралып бара.
–Урман бетсә, ни кала? – дип
Мин дә сораурга калам,
Уйлый торгач киләчәккә
Дөрес юл эзләп табам –
Һәм тиздән расчет алам.
Язның матур көннәрендә
Чит җиргә чыгып таям.
Әти елап, кулын болгап
Мине озатып кала,
Мин бит аның таянычы –
Кадерле газиз бала.
Саубуллашкан минутларда
Күзеннән яшьләр ага.
Ул мине кочып алганда:
– Күрешә алмабыз…, – дигән сүзе
Күңелемә шик сала.
Мин шулай да тынычланып
Чит якларга юл алам,
Чөнки әле өч абыем

Аның янында кала.
Әмма-ләкин әйткән сүзе
Зар-сагыш булып кала:
Дүрт айдан соң вафат булып
Бу дөньядан югала.
Аның әйткән соңгы сүзе
Ятим калган йөрәгемә
Мәңгелек сала яра.
Шул елларны Агарзяда
Урман киселеп бетә,
Бөтен халык өй-мал ташлап,
Бер-бер артлы бәхет эзләп
Чит илгә чыгып китә.
Әти үлгәч абыйларым
Таралды төрле якка,
Агарзяда калмадылар
Бер нинди туган зат та,
Әти генә – мәңгелеккә
Торып калды зиратта.
Инде аның каберен дә
Табып булмас эзләп тә,
Ә шулай да ышанамын
Табырмын, дип бер шәптә.
Әтиемнең истәлеген
Яздым мин өстән генә,
Язмый калган хәсрәтләрен,
Аның күргән михнәтләрен
Беләм тик үзем генә.

***

Әти безгә үрнәк булды,
Гел яхшыга өйрәтте:

–Кешенең энәсенә дә
Кулыгызны салмагыз, дип
Бармак янап кисәтте.

Үлчәгәндә мул үлчәде,
Үлчәүгә ким салмады,
Хәләл көче белән тапкан
Малын алдап сатмады,
Ашаганы хәләл булды –
Хәрам ашын капмады.

Кулына алып тәмәке дә
Гомер буе тартмады,
Исерткеч эчемлекләрнең дә
Кирәклеген тапмады.

Безнең әти бер кайчан да
Нык кычкырып көлмәде,
Һәр вакытта тыйнак булды,
Телләшмәде-тиргәшмәде,
Яман сүзне белмәде.

Яман сөйләгән кешедән
Чирканып ерак торды,
Сүзләренә «колак салмый»
Читкә барып утырды.

Ялган сөйләгән кешене
Аның җаны сөймәде,
Исереккә кул бирмәде,
Сәламен дә алмады,
Яшәде ул гади генә,
Мин әллә кем димәде.

Ул безне дә үзе кебек:
–Игелекле булыгыз, – дип
Изгелеккә өндәде.

***

Минем әти изге булды –
Атна кичен дөнья куеп
Җомга көнне җыелды.

## Казый балтасы

**Ахун, Каюм, Истәк һәм башка**
**Төй буе авылларына багышлыйм.**

Үскән авылымның елгасында
Череп акты күпер тактасы,
Тамыр җәйгән нигез казыгына
Килеп чапты «казый» балтасы.

Төй буйлары буйлап – күп авылның
Тамырларын өзде илнең патшасы,
Кешеләре елап илгә таралдылар –
«Елап» калды авыл капкасы.

Ирексезгә калып – каза күргән
Заманалар күптән уздылар,
Нигез чапкан явыз «казыйларны»
«Казык» белән эштән кудылар.

Ләкин җанга якын якташларым
Туган җирсез торып калдылар,
Ирексездән китеп чит илләргә,
Төй буйларын моңга салдылар.

Югалдылар китеп еракларга
Дус-ишләрем, туган-затларым,
Йөрәкләрдә калды моңлы сагыш –
Төй буйлары – туган якларым.

Беткән авылларга һәйкәл итеп
Куяр идем авыл капкасын,
Авыл нигезенә казык кагып
Эләр идем исем тактасын.

## Күңелең бит яшь әле

Мин картайдым димә әле –
Күңелең бит яшь әле,
Яшьлегеңдә янган кебек
Тагын янып яшә әле.

Канатыңны төшермә әле –
Төшенкегә төшмә әле,
Һаваларга очмасаң да
Җир йөзендә яшә әле.

Учагыңны сүндермә әле –
Сүнмә әле – сүрелмә әле,
Кочагыңны җәеп яшә –
Картлыкка бирешмә әле.

Картайдым дип үкенмә әле –
Күңелең бит яшь әле,
Үкенечкә калдырма әле –
Бер кабынып яшә әле.

## Күңелем бураннары

Авылыма кайтып киләм –
Ерып кар бураннарын,

Колач җәеп каршы ала
Авылым урамнары.
Авылым урамнары –
Күңелем бураннары,
Йөрәгемне басам әле
Бер урап урамнарны.

Сәлам биреп каршы ала
Олы-Елга ярлары,
Бураннарда ярсып ява
Авылымның карлары.

Яр буена тезелгәннәр
Туган як чыршылары,
Буран көенә җырлыйлар –
Авылым «җырчылары».

Авылыма сәлам бирәм
Туктатып бураннарны,
Күңелемә илһам бирә
Туган як урманнары.

Авылым урманнары –
Күңелем бураннары,
Йөрәгемне басам әле
Бер урап урманнарны.

## Соңгы уйлар

Гомер елларыңны искә алып
Үткән юлларыңнан үтәрсең,
Гомер йомгагыңны искә алып,
Уйларыңда кабат сүтәрсең.

Үткән елларыңны уйлаганда
Су буена туктап үтәрсең,
Бала чакларыңны искә алып
Ярларында уйнап китәрсең.

Очратырсың барган юлларыңда
Шаулап үткән сабан туйларын,
Ишетерсең шулчак сайраганын
Басуларда сабан тургаен.

Яшьлек язларыңны уйга салып,
Язларыңнан кабат үтәрсең,
Яшьлек ярларында учак ягып,
Сөйгәнеңне янып көтәрсең.

Искә алып тәүге мәхәббәтне
Хисләреңдә назлап сөярсең,
Кире кайтып яшьлек елларыңа
Тагын янып,тагын сүнәрсең.

Яшьлегеңнең үткән язларында
Ташкын булып ташып агарсың,
Күзләреңнән тулып яшьләр тамар –
Уйларыңда шашып янарсың.

Тирән уйга батып, яшьлегеңнең
Диңгезенә чумып йөзәрсең,
Яшьлек елларында торып калган
Дусларыңны, бәлки, эзләрсең.

Күңел канатыңны бер җилпенеп
Яшьлегеңә кагып алырсың,

Ләкин алар мәңге кире кайтмас –
Уйларыңда торып калырсың.

* * *

Бала чактан алып – хәзергәчә
Үткәннәрне тезеп килерсең,
Гомереңнең соңгы көзләрендә
Уйларыңда йөзеп йөрерсең.

Гомер юлыңдагы хаталарны
Хисапларга үзең салырсың,
Үлем түшәгенә менеп яткач –
«Түшәмеңә» язып барырсың.

Үткән елларыңны язган чакта
Бер җирендә туктап калырсың,
Җир йөзенә чәчкән орлыгыңның
Җимешләрен җыеп алырсың.

Җыеп алган барча уңышыңның
Сыйфатларын үзең күрерсең,
Җимешеңне вакыт бизмәненә салып
Үзеңә син бәһа бирерсең.

Бизмәнеңнең мисалына тугры карап
Тирән уйга, бәлки, төшәрсең,
Үкенечләр калыр соңгы уйларыңда –
Терсәгеңне , бәлки, «тешләрсең».

Яшәвеңнең соңгы көннәрендә
Син Ходайның «колы» булырсың,
Гомер буе өстен яшәсәң дә,
Кулың сузып дога кылырсың.

Үткәннәрне уйлап сусаганда
Соңгы йотым суың эчәрсең,
Соңгы минутларың кичергәндә
Шыбыр суга, бәлки, төшәрсең.

Әгәр булса якын туганнарың –
Соңгы тапкыр килер күрәсең,
Соңгы юлга сине озатырлар
Моңга салып ясин сүрәсен.

## Кайтып барам

Мин бәхетле – берүземә
Дүртәү минем авылым:
Ахун авыл, Каюм, Истәк –
Алар – үскән авылым,
Олы-Елга буйларында –
Анысы туган авылым.

Дүрт авылым дүрт туган –
Минем өчен бертуган.
Берсе – Аркабаш тавының
Итәгенә сузылган,
Калганнары – Төй буенда –
Күңелемә уелган.

Әх, авылым-авылларым,
Мин сезне сагынамын,
Туган якларыма карап
Кош булып кагынамын,
Тагын сезне бер күрергә
Ходайга табынамын.

Ходай миңа насыйп итте –
Авылга кайтып барам,
Төй буйлары авылыма –
Өзелде минем ара,
Олы-Елга ярларында
Тукталып торып калам.

## «Бисмиллә»не кушыгыз

Онытмагыз «бисмиллә»не,
«Адым» саен укыгыз,
Юлыгызга: – Бисмилләhи…, – дип
Ишек атлап чыгыгыз.

Юлдаш итеп юлыгызга
Иман нурын кушыгыз,
Караңгыда якты булыр
Сезнең барган юлыгыз.

Кайгы-хәсрәт килгәндә дә
«Бисмиллә»не укыгыз,
Шатлык хисе исертсә дә
Айнык булыр ушыгыз.

Калдырмагыз «бисмиллә»не,
Эш башына кушыгыз,
Кайгыда да, шатлыкта да
Булсын сезнең дустыгыз.

– Бисмиллә, – дип шигырь яздым –
Кабул итеп укыгыз,
Чын күңелдән саулык телим –
Сау булыгыз – хушыгыз.

## Заманым сагышлары

Чакыралар үткәннәргә
Заманым сагышлары –
Безнең үткән замананың
Авазы тавышлары.
Заманым сагышлары –
Гомерем агышлары.
Еллар аша ишетелә
Үткәннең тавышлары.

Чакыралар шул елларга
Яшьлегем тарафлары,
Яшьлегемдә сөйгәнемнең
Сөйкемле карашлары.
Заманым сагышлары –
Яшьлегем агышлары.
Яшьнәп үткән яшьлегемнең
Югалту табышлары.

Хәтерләтә үткәннәрне
Күңелем сагышлары,
Шул әрнетә күңелемне –
Гомерем ялгышлары.
Заманым сагышлары –
Гомерем язмышлары,
Гомеремне ялгыз узган
Язмышымның моң-зары.

## Бастырык

Бүген төнлә төшләремә
Килеп керде бастырык –
Печәнгә китеп барамын
Җиккән атым чаптырып,

Кулларымда озын аркан,
Ә астымда – бастырык.

Каезланган каен ыргак
Уйнап бара ялтырап,
Арба артына тагылган –
Арба бара шалтырап,
Мин астыма мендәр салдым –
Бастырык бит катырак.

Печәнемне таптап төйим
Арба читен арттырып,
Уртасына сузып салдым
Бастырыкны яткызып,
Аркан белән бәйләп куйдым
Бастырыкка бастырып.

Алып кайтып – йөк башында
Бастырык бавын чишәм,
Арт ягымнан арканымны
Кемдер тартканын сизәм,
Бастырык астында калган
Арканны тартып өзәм.

Бастырыкка бастырылып
Торып бастым аптырап,
Яткан ястыгыма карап
Басып торам – калтырап.

Шуннан бирле төн йокымны
Мин Ходайга тапшырам,
Кичтән – белгән догаларны
Укып яту яхшырак.

## **Кайттым туган ягыма («Танып»)**

Изге чишмә суын эчтем
Бала-чага чагымда,
Болын чәчкәләрен җыйдым –
Чәчкәле тугаенда.

«Танып» дигән шифаханә
Үсеп чыкты ярында,
Җаен табып еллар аша
Кайттым туган ягыма,
Нурлы биналарны күреп
Күңелгә нур агыла,
Бала чагым искә алып
Суын эчәм тагын да.

Башым иеп сәлам бирәм
Туган як ярларына,
Искә алып кайтам шул чак
Яшьлегем таңнарына.

Күзем талганчы карыймын
Яшьлегем ярларына,
Күзләремнән тамчы тама
Үткәннең моң-зарына.
«Танып» дигән шифаханә
Үсеп чыкты ярында,
Җаен табып еллар аша
Кайттым туган ягыма,
Нурлы биналарны күреп
Күңелгә нур агыла,
Бала чагым искә алып
Суын эчәм тагын да.

## Изге чишмә

Изге чишмә буйларында
Юган идем күземне,
Һәр ел саен килермен дип
Биргән идем сүземне.
Хәзер сине «Танып» диләр
Үзгәртеп исемеңне,
Ярларың да бик үзгәрде –
Танып булмый үзеңне.

Булды шундый заманалар –
Сөймәделәр үзеңне,
Читтән килеп – кара йөзләр
Капладылар йөзеңне.
Хәзер сине «Танып» диләр
Үзгәртеп исемеңне,
Ярларың да бик үзгәрде –
Танып булмый үзеңне.

Күмгән җирне ярып чыкты –
Изге чишмә түземле,
Җиргә ятып суын эчәм –
Юатамын күңелне.
Хәзер сине «Танып» диләр –
Таныт әле йөзеңне,
Шифа суларыңны эчеп
Танысыннар үзеңне.

## Аңлый алмыйм

Аңламыймын бу дөньяга
Ни өчен килгәнемне,

Тәмле йокымнан уянып
Дөньяны күргәнемне.

Аңлый алмыйм йолдыз булып
Атылып төшкәнемне,
Җир йөзендә бер минутка
Кабынып сүнгәнемне.

Бәлки аңлармын соңырак
Ни өчен килгәнемне,
Мәңгелеккә кире кайтып,
Сөйләрмен күргәнемне,
Сөйгәнемә серне ачып,
Сөярмен сөйгәнемне.

## Кайда сез, каеннарым?

Туган якларыма кайтып
Су буйларын буйладым.
Су буендагы каеннар
Көтәләр, дип уйладым.
Кайда соң сез, бала чакта
Яраткан каеннарым,
Авылымның кайгыларын
Тараткан каеннарым?
Бала чакларымда калган
Эзләрем табалмадым,
Каен җиләген тезләнеп
Эзләдем – кабалмадым.
Кайда соң сез, кулларыма
Җыелган җиләкләрем,
Мөлдерәмә күнәгемнән
Коелган җиләкләрем?

Үткәннәргә кире әйләнеп
Кайта минем уйларым...
Бала чакларымда үткән
Кайда икән юлларым?
Кайда соң сез, шаулап үскән
Балачак каеннарым,
Каенлыкта шау-гөр килеп
Шаярган бала чагым?
Кайда сез, каеннарым?

## Яз бәйрәме

Бүген бәйрәм, яз бәйрәме,
Гади генә көн түгел:
Язгы хыялларга чумып,
Шатлыкка тулган күңел.
Бүген хатын-кыз бәйрәме –
Килгән язларның яме,
Гүзәл затларның йөзләрен
Бизи чәчкә бәйләме.
Кулларында гөлләмәләр –
Бүләк итеп биргәннәр,
Иңнәренә кулын салып:
– Иң кадерлем, – дигәннәр.

Котлыйм сезне бәйрәм белән,
Сихри матур гүзәлләр.
Сөю хисе балкып торсын,
Безне өзелеп сөйгәннәр.
Яшәгез сөенеп кенә,
Гөлгә күмелеп кенә,
Иркә булып иркәләнеп,
Сөеп – сөелеп кенә.

Кайнар сөю, саф мәхәббәт –
Сезгә шул теләк кенә,
Яшәгез дөньяны ямьләп,
Тәмле сүз сөйләп кенә.

**Агым суда йөзмәгез**

– Язмышыма язылган, – дип,
Агым суда йөзмәгез.
Каршы йөзеп язмышларны
Чәчкәләргә бизәгез.
Язмышларга пар булырлык
Парыгызны эзләгез,
Язмыш юлларын ялгышып
Чәчкәләрне өзмәгез.

Ялгызлар ярында калып
Сагышларда йөзмәгез,
Яшьлек ярларында калган
Ярыгызны эзләгез.
Сабыр сагышка сабышып
Гомер юлын үтмәгез,
Сабырлык сары алтын дип,
Сабыр итеп түзмәгез.

Язмыш үзе куша диеп,
Ялгышмагыз үзегез,
Ялгыш язмышны төзәтеп
Гомер юлын үтегез.
Баштан башлап язмышларны
Үзегез алдан языгыз.
Башкаларга өлге булып
Калсын сезнең эзегез.

**Кече-Елга урманы**

Кече-Елга. Кара урман
Ябынган кышкы юрган,
Утын чана карны яра --
Җигелгән кара юрга.
Ачы еллар – ачлык еллар,
Бөтен дөнья кап-кара,
Коры чыршыларны карап
Әти утынга бара.

Мин янында – кече бала
Тунын киеп утырам,
Кулларымда кара икмәк --
Авызыма тутырам.
Кече-Елга. Кара урман,
Сызгыра ачы буран,
Ач корсакка авыз ачып
Туңган икмәкне «борам».

Әти мәрхүм утын кисә
Кече-Елга буенда,
Сары саплы үткер балта
Уйный аның кулында.
Атын борып утын төйи –
Бияләе кулында.
Аркан белән кысып бәйли –
Мин әйләнәм кырында.
Буран улый, кар тутыра,
Кышкы урман юлына,
Бияләен салып бирде
Кече газиз улына.

* * *

Кече-Елга юлы бара...
Юл буе кышкы дала.

Бала чанасына төяп
Утын ташый бер бала.
Эзе югала артыннан,
Буран сыпырып бара,
Тукталып туңган кулларын
Өреп җылытып ала.
Тагын ял итеп ала да
Алга таба юл ала.
Барган юлы да югала –
Ерак бит әле ара.
Ачы буран – урман юлы –
Авыр сугыш еллары.
Авыр чана тартып кайта
Бала-чага куллары.
Кече-Елга. Кара урман.
Салкын сугыш еллары.
Йөрәкләргә җылы бирде
Шул урманның «юрганы».
Ачы еллар – ачлык еллар –
Җуелмый хатирәләр.
Күпме еллар үтсәләр дә
Йөрәкне әрнетәләр.

## Яшьлегем миләшләре

Юл буенда зифа миләш –
Киеме кызыл тәлгәш,
Үсмер яшьле кызлар сыман
Кызарып үсә миләш.
Юл өстендә ялгыз миләш.
Өзәм әле тәлгәшен,
Яшьлек елларымны тезәм –
Мөлдерәмә күз яшем.

Кулларымда тәлгәш-тәлгәш
Кызарып пешкән miләш,
Яшьлек елларында сөйгән
Кызларым сиңа тиңдәш.

Үткәннәрнең моңы булып
Коела кызыл миләш,
Җуелмый яшьлек еллары –
Бирче миңа бер киңәш.
Миләшләрем – тиңдәшләрем,
Сез минем көндәшләрем,
Яшь чагымда яшьлегемнән
Көнләшкән миләшләрем.
Тәлгәш-тәлгәш кызыл миләш
Туып үскән якларым.
Әйтегезче, миләшләрем,
Кайларда яшь чакларым?

## Әйдә языйк гариза

Һәр көн иртә зифа буйлы
Бер кыз урамнан уза.
Исеме дә чәчкәгә тиң
Дип әйтәләр – Роза.
Әй, Роза, Роза, Роза,
Мине читләтеп узма,
Бер күрешеп сөйләшергә
Сиңа «тешләрем сыза».

Бер көн сине күрми торсам
Ярсып йөрәгем кыза,
Сине күрергә ашыгам –
Артымнан тузан туза.

Әй, Роза, Роза, Роза
Гомерем зая уза.
Ялындырма – бул риза,
Әйдә язьийк гариза.

Бер риза, бер түгел диеп
Минем кәефне бозма,
Яшь гомерләр узып бара,
Эшне озакка сузма.
Әй, Роза, Роза, Роза,
Минем кәефне бозма.
Ялындырма – бул риза.
Әйдә язьийк гариза.

Роза чәчкәләре төшкән
Кигән күлмәгең туза,
Синең дә бит миңа күптән
Сизәм – күзләрең кыза.
Әй, Роза, Роза, Роза
Гомерләр зая уза,
Син ризамы? Мин риза –
Әйдә язьийк гариза.

## Ике бәла

**(тәнкыйть)**

Ике кыз сата кибеттә –
Берсе исереп ята.
Берсе Аля, берсе Валя –
Икесе ике бәла.
Уртага суккан еландай
Нишләргә белми «нәнә».
«Нәнә» дигәне кызларга
Кибетнең баш мөдире:

–Нәфсегезне тыймасагыз –
Эштән куармын, – диде.
Сабыр канатлары сынгач –
«Нәнә» нишләсен инде.
Ике бәланең «нәнә»се
Сүзне тотты бик кыска:
-Хватит сезгә кимерергә
Минем җилкәне бушка!
Бармак янап әйтеп куйды:
–Бик сикермәгез башка.
Әмма-ләкин ике бәла –
Икесе – ике «кәҗә».
Киртә аша сикерәләр –
Күрмиләр бәла-каза,
Кәбестәне кимерәләр –
Оныткач «нәнә»–хуҗа.
Хуҗа сүзен җил очыргач –
Нигә күрсеннәр нужа.

## Яшьлеккә кайтыйк әле

Урам буйлап гармуныңны
Бер уйнап үтсәң иде,
Безнең заман кызларының
Үзәген өзсәң иде.
Яндыр әле йөрәкләрен –
Яшьлек кайтсын яңадан.
Яшьлек җырларын яңартып
Җырлап үтик яңадан.
Керсен өйгә яшьлек яме,
Сирень чәчкәсе тәме,
Иреннәрдә тойгы тусын –
Беренче сөю тәме.

Саклана дәрт йөрәкләрдә –
Яшьлек үтеп китсә дә,
Үткәннәрне үкендереп
Картлык килеп җитсә дә.
Уят әле яшьлегемне,
Юат күңелләремне,
Уйнат исемә төшереп
Күңелле көннәремне.
Тартып уйна гармуныңны –
Җәлләмә сәдәпләрен,
Гармун тавышлары әйтә
Яшьлегем сәгатьләрен.
Гармуныңның кыңгыравы
Яшьлек тавышы сыман,
Кыңгыраулы яшьлек чыңы
Колакта чыңлый һаман.

## Тагын, тагын кызыгыз

Изге булсын уегыз,
Котлы булсын туегыз,
Берәү түгел, игезәкләп
Туып торсын улыгыз.
Алга юллар сызыгыз.
Тагын план корыгыз,
Тагын да бер кызып алып,
Тагын тусын кызыгыз.
Бер кыз бала бизәк кенә –
Тагын, тагын кызыгыз.
Шаулап үскән шат балалар –
Гаилә бизәге алар.
Иман – тәрбия нигезе,
Булмас аларга зарар.

## Озату

Кара кайгы – канлы сугыш бара,
Илебезнең авыр еллары.
Ир-егетләр китә яу кырына –
Өрлек кебек авыл уллары.

Парлап җиккән кара атлар килә,
Көмеш төймә, кара йөгәннәр,
Кара дугаларга пар кыңгырау,
Үтә кызыл әләм элгәннәр.

Озаталар яуга сылу кызлар,
Көтәрмен дип вәгъдә биргәннәр.
Зәңгәр читле алсу кулъяулыклар
Ат ялына чигеп үргәннәр.

Җылы нурын сибә җәй кояшы,
Чәчкә аткан бакча гөлләре,
Сузып уйный моңлы тальян гармун,
Елый аның көмеш телләре.

Урам буйлап килә кырыс атлар,
Озатып бара авыл яшьләре.
Кара кайгы – илдә сугыш бара,
Яшермиләр кайнар яшьләрен.

Авылымның кыю егетләре
Урамнарны җырлап үттеләр,
Җәй аеның ямьле көннәрендә
Яулык болгап, яуга киттеләр.

Озаттылар газиз аталарны
Туган илнең тулпар атлары,

Сугыш кырларында ятып калды,
Корбан булды алар, кайтмады.

Кайтмадылар, китеп югалдылар,
Җиңү язы чәчкә атса да.
Гомер буе көткән аналарның
Чәчләренә аклар ятса да,
Яшьли калган ятим балаларның
Күзләреннән яшьләр акса да.

## Тагын бер күрәм әле

Бер күрүдә гашыйк булып
Карадым йөзләреңә,
Ялгыш түгел – язмышымны
Эзләдем күзләреңнән.
Карадым йөзләреңә дә,
Сөрмәле күзләреңә.
Бәлки син дә сүз кушарсың
Сөйкемле сүзләремә.

Тагын да бер киләм әле,
Сине бер күрәм әле,
Өлкән яшемдә булсам да,
Миндә яшь йөрәк әле.
Яшим әле, көләм әле,
Кемнедер көтәм әле.
Калган гомер елларымны
Елмаеп үтәм әле.

Талган түгел, дөрләп янган
Миндә яшь йөрәк әле,
Ялган түгел, чын күңелдән
Кемнедер көтәм әле.

Дөрләп янган йөрәгемә
Әлегә түзәм әле,
Тагын да бер сине күреп
Серемне чишәм әле.

**Миңа син рәнҗемә**

Себер яклары ачы җил,
Үзәккә үтә салкыны,
Туңдыра, өреп сүндерә
Йөрәктәге ялкынны.
Әй, Мәнзүмә, Мәнзүмә,
Язам сиңа тәрҗемә,
Язмышыңны үзең яздың –
Миңа син рәнҗемә.

Киткән чакта сау бул, диеп
Карадың күзләремә,
Югалдың китеп Себергә,
Кар яуды эзләреңә.

Себер якларына карап
Эзләдем эзләреңне,
Сезнең яктан искән җилләр
Өзделәр үзәгемне.

Себер юллары пыяла –
Барсам аягым тая,
Чакырсам, тавышларымны
Җил ала әллә кая.
Әй, Мәнзүмә, Мәнзүмә,
Китеп югалдың кая,
Кошлар да бит илләренә
Кайтырга юллар таба.

Себер җилләре себереп
Җуйдылар эзләреңне,
Шигырьләрем сөйләп бирер
Җыелган серләремне.
Әй, Мәнзүмә, Мәнзүмә,
Язам сиңа тәрҗемә,
Язмышыңны үзең яздың –
Миңа син рәнҗемә.

## Олы-Елга

Туган ягым моң елгасы,
Авылым – Олы-Елга,
Күңелемә моңнар салып
Озаттың олы юлга.
Олы-Елга моңнар булып
Уелган минем уйга,
Синең елга буйларында
Моңланып үстем буйга.

Туган якның гүзәллеге
Күңелемә тулышкан,
Авылымның «моңлы» суын
Җырлап эчтем тумыштан.
Олы-Елга моңлар булып
Уелган минем уйга,
Синең елга буйларында
Моңланып үстем буйга.

Граннар як басуларын
Чокырлы кырларын да,
Исемен дә моңга салып
Җырлыймын җырларымда.

Олы-Елга моңлар булып
Уелган минем уйга,
Синең белән горурланам,
Гомерем буйларына.

Бары тик сиңа багышлыйм
Сагышлы җырларымны,
Киләчәккә мирас итәм
Моң тулы җырларымны.
Олы-Елга – моңлы елга,
Сагынам юлларыңны,
Үткәннәрне моңга салып
Калдырам моңнарымны,
Үткәннәрне җырга салып
Калдырам елларымны.

**Уйна әле гармуныңны**

Ишетелми тальян моңы,
Заманалар уздымы?
Әллә гармунчылар белән
Гармуннар да туздымы?
Уйнамыйсың гармуныңны –
Әллә гомер уздымы?
Гомер юлларың узганда
Бармакларың туздымы?

Уйнат әле бер өздереп –
Урам көен суз әле,
Картлыгыңны дер селкетеп
Урамнардан уз әле.
Уйна йөрәкләрне өзеп –
Күреге түзәр әле,

Гомер буе түзгән йөрәк
Әле дә түзәр әле.

Уйнат әле яңгыратып
Авылымның кичләрен,
Төшер әле исләремә
Яшьлегемнең хисләрен.
Килсен әле күз алдына
Сөйгәнемнең күзләре,
Яңгырасын ераклардан
Сөям дигән сүзләре.

Җәйнең зәңгәр кичләрендә
Күтәрелә күк томан,
Шул томаннар арасыннан
Яшьлегем кайтыр сыман.
Узып киткән яшьлегемнең
Хыялларында янам,
Зәңгәр күзле гармунчыны
Оныта алмыйм һаман.

## Юл чишмәсе

Туган ягым – чишмәле як.
Юл буенда да чишмә.
Авылымның юл чишмәсе
Һаман да яши истә.
Юл буенда чылтыр чишмә
Уелган хисләремә,
Туган ягымның моңлары
Чылтырап ага истә.

Юл буенда салкын чишмә –
Суын юлчылар эчә,

Чишмә суын эчеп үскән
Елларым искә төшә.
Туган якның чишмәләре
Чылтырый исләремдә,
Көмеш сулы юл чишмәсен
Эзлимен төшләремдә.

Еракларга киткән чакта
Озатып калды чишмә,
Юл чишмәсе – моң чишмәсе
Чыкмас күңелдән һич тә.
Сагынсагыз юл чишмәсен –
Сагышларга түзмәгез,
Юл чишмәле туган якка
Кайту юлын эзләгез.

## Буйсынмаган мәхәббәт

Дөрләп янган мәхәббәтем,
Яна да тагын сүнә.
Үтәлмәдем тормыш юлын
Тик синең белән генә.
Эх, Тәкъсинә, Тәкъсинә,
Ниләр булды соң миңа?
Сиңа булган мәхәббәтем
Бер кабына, бер сүнә.

Бергә чаклар күз алдында,
Бүгенге кебек сыман,
Әллә шуңа еллар аша
Күңел сине юксына.
Эх, Тәкъсинә, Тәкъсинә,
Ниләр булды соң миңа?

Сиңа булган мәхәббәтем
Бер кабына, бер сүнә.

Сөю тормышка ашмады,
Каплады куе томан.
Син дә миңа томан аша
Елмаеп торган сыман.
Эх, Тәкъсинә, Тәкъсинә,
Ниләр булды соң сиңа,
Миңа булган мәхәббәтең
Бер кабына, бер сүнә.
Эх, Тәкъсинә, Тәкъсинә,
Ни булды икән безгә,
Буйсынмаган мәхәббәтне
Җиңәрбез төсле бергә.

**Тынмасын азан моңы**

Һәр көн иртән таң алдыннан
Тын калып тыңлыйм азан,
Илебезгә көтмәгәндә
Килде азанлы заман.
Яңгырый азан моңнары
Мәчет манарасыннан,
Ишетелә изге тавыш
Гасырлар арасыннан.

Кире кайттык динебезгә
Илебез карашыннан,
Тыңлыйбыз азан моңнарын
Азатлык арасыннан.
Күңелләрдә зур аяныч
Сакланып килә һаман,

Үткән елларым азансыз –
Заяга үткән заман.

Илебезгә нигез сала
Яңа мәчет, биналар,
Илгә изге теләк теләп
Илне бизәп торалар.
Күтәрелә манаралар,
Иман нурлары алар.
Безне намазга чакырып
Азан әйтәләр алар.

Яңгырасын азан моңы
Илебезгә нур чәчеп,
Килсен безгә иман белән
Киләчәккә зур бәхет.
Тынмасын азан тавышы –
Динемә тугры калам,
Яңгырасын илебездә
Җиткәнче ахырзаман.

**Аркабаш тавы аша**

Кайтыр юлларым сузылган
Аркабаш тавы аша,
Кайтырга туган ягыма
Күңел ашкынып таша.
Аркабаш таулары биек,
Кайтам башымны чөеп,
Туган якның язгы җиле
Назлый аркамнан сөеп.

Сусап кайтам туган якка,
Басу юлларын кичәм,

Туган якның җилләренә
Сагышларымны чишәм.
    Аркабаш таулары аша
    Туган авылыма төшәм,
    Чишмә тавышларын тыңлап
    Көмеш суларын эчәм.

Туган якларымда туды
Минем тәүге җырларым,
Җырларыңны чит илләрдә
Җырлый синең улларың.
    Аркабаш таулары аша
    Тәүге йөргән юлларым,
    Сине сагынып читтән кайта
    Читән үргән улларың.

## Менә сиңа аулак өй

Күзем төште бер бичәгә –
Чамалы гына хатын,
Күптән үзен чамаларга
Әйләнеп йөри башым.
    Ул да ялгыз, мин дә буйдак,
    Икебез дә бик тыйнак.
    Якынырак танышырга
    Йөримен күптән уйлап.
Бердәнбер көнне бу хатын
Сорады мине җайлап:
–Күтәр әле капчыгымны –
Кайтырбыз икәү парлап.
Ничек инде тыңламыйсың:
Күзләрен тора майлап.
    Тутырылган зур капчыгын
    Алып салдым иңемә,

Сораганын чит какмадым –
Киттем атлап өенә.
Мин капчык күтәреп барам,
Бу хатын алдан чаба,
Аңламый шул хәлләремне –
Минең хәл бит бер чама.
Ач корсакка авыр капчык –
Чамалап уйлап кара.
Якынайдык өй янына –
Хәлләр булса да чама.
Өйләрендә ут күренми –
Башка өйләрдә яна.
–Әллә бүген аулак өй? – дип
Сорау бирдем мин аңа.
Ишетмәгәнгә салышып
Миңа эндәшми, бара.
Капка төбенә җитәбез –
Якыная бит ара.
Бу чынлап та ачкыч эзләп
Кесә төбен актара.
Кинәт кенә башка сукты:
Значит бүген «пора».
Әһә, мин әйтәм, эләктем
Бүген аулак өенә.
Ни әйтсә дә шуны тыңлыйм –
Биим аның көенә.
Җайлап кына ишек ачып
Кердек чолан өенә.
Мин капчыкны иплэп кенә
Куйдым бүлмә буена.
Карап торам – бу ишекне
Элдермәскә җыена.

Чолан ишеген бикләми –
Ачып куйды иңенә,
Әх, инәңнең кодрәте,
Кертми дә бит өенә.
Бик елмаеп карасам да
Юл бирмәде түренә,
Кырма бүрегемне салып
Элә алмадым чөенә.
Авызымны чөйгә элеп
Калдым ишек төбендә.
　　Аңлап булмый хатыннарны –
　　Бер дә юкка сөенә,
　　Сөеп-сөелер урынга
　　Янган утта көелә.
–Я, алайса сау бул, – диеп
Киттем башымны иеп,
Кайтамын тетмәсен тетеп,
Йөри дип борын чөеп.
　　Борын төшкән, кәеф бозык,
　　Барам урамнан кызып,
　　Уйларымнан бу бичәне
　　Ничек ташларга сызып?
Кемгәдер бәхетне Ходай
Бирә тутырып, өеп,
Әллә мине Алла суккан –
Йөримен янып-көеп.
Әллә инде бу бичәләр
Башка якны чамалый?
Буем да бар, төсем дә бар –
Белмим нидер ярамый,
Башка төрле уйлар керә –
Менә сиңа аулак өй.

## Кече абый

**Мәрхүм Әдеһәм абыйга арналган**

**Исләремдә синең менгән атың,**
**Ялын сирпеп очар канатың,**
**Энем диеп: әллә җан атканга –**
**Җаным белән сине яраттым.**

Менгән атың – иярсез ат,
Кулда егет камчысы,
Тормыш юлың – сыңар канат,
Гомереңнең ачысы.
Кече абый – үзе сабый,
Мин иярчен энесе,
Бала чакларымнан алып
Булды үрнәк өлгесе.
Кече абый – бертуганым
Искә төшә бигрәк.
Исән чакта туганнарның
Кадерен белергә кирәк.
Тормыш юлың – ике улың,
Ике ятим калучы,
«Ялгыз аккош» – синең язмыш,
Кайгыларга салучы.
Берсе Әдип, берсе Әниф,
Икесе дә әдәпле,
Төптән уйлап үзләштергән
Синең төпле гадәтне.
Минем хәтер – ике кабер,
Берсе сине көтүче (җиңги)
Бара юлың, ике улың –
Кадер-хөрмәт итүче.

Әле ярый кече абый
Төшемә керә сирәк,
Болай да бит өннәремдә
Юксынып тибә йөрәк.

**Сатучы кыз**

Алма үлчи, алма сата
Сатучы кыз Лариса.
Аның йөргән юлларында
Алсу гөлләре үсә.

**Кушымта:**

Аллар үсә Лариса,
Гөлләр үсә Лариса,
Ал чәчкәләр бирер идем,
Сиңа дигән мәхәббәтем
Киләчәктә бар дисә.

Киштәсенә тезеп куйган
Алма, хөрмә һәм банан,
Бер күрүдә гашыйк булдым,
Сөю утында янам.

**Кушымта.**

Сатулашмый алыр идем,
Әгәр дә киләм дисә,
Үземнеке булыр әле –
Әгәр Алла теләсә.

**Кушымта.**

Алма үлчи, алма сата
Бик матур кыз Лариса,
Ал чәчәкләр бирер идем --
Сиңа дигән мәхәббәтем
Киләчәктә бар дисә.

**Нәзилә дигән идем**

Яшь чагымда яшерен генә
Мин сине сөйгән идем.
Әллә артык яратканга
Гел янып-көйгән идем.

Нәзилә дигән идем,
Гомерлек дигән идем.
Йөрәгемне бүләк итеп
Бирермен дигән идем.
Нәзилә, дигән идем,
Үземә дигән идем.
Синнән башка яшь гомерем
Үтәр димәгән идем.

Бәлки соң түгелдер әле:
Хисләр һич җуелмаган,
Безнең сөю гөлебезнең
Чәчкәсе коелмаган.

Яныңа килер идем,
Кулымны бирер идем,
Бәлки син дә кабул итеп
Кулыңны бирер идең.
Нәзиләм, дияр идем,
Өзелеп сөяр идем,
Назлы чәчкәләрне өзеп
Алдыңа өяр идем.

– Гомерлек сөйгән ярым, – дип,
Гөлләргә күмәр идем.
Тагын да сине яратып
Гел янып-көяр идем.



Баян абый, мин һәм Хатип абый.



Мин (уңда) армияда иптәшем белән.



Фатима жиңгә һәм Хатип абый.



Әдеһәм абый һәм Зыяфа жиңгә.

## Тик өзелмәсен ара

Көтәм сине һәр көн, иркәм,
Нигә килмисең икән.
Аралар ерагая бит,
Әллә сөймисең микән.

**Кушымта:**
Әй, Динара, Динара,
Салдың йөрәккә яра.
Сукмакларга кар яуса да,
Салкынаймасын ара.
Әй, Динара, Динара,
Ерагаймасын ара.
Салкын карны эретерлек
Табарбыз берәр чара.

Яралы йөрәгем ярсып,
Күмердәй кызып яна.
Ялындырма, кил яныма –
Гомерләр узып бара.
**Кушымта.**

Серле күзең, нурлы йөзең,
Кигән киемең кара.
Кар сулары эреп агар –
Тик өзелмәсен ара.
**Кушымта.**

## Сөйгәнем юк янымда

Утырдым каен төбенә
Бер ялгызым сөялеп,
Юксынып йөрәгем яна –
Янымда юк сөйгәнем.

**Кушымта:**
Сөйкәлмәгез каеннарга –
Ялгыз каен кайгыга,
Ялгыз каеннарга тиңдәш
Күктә йөзгән Ай гына.
Сер чишмәгез каеннарга,
Төшмәгез кайгыларга,
Чишмә суларын парлашып
Эчүләре җай гына.

Яз аенда серләремне
Сөйлим ялгыз каенга.
Каен суын ялгыз эчәм –
Сөйгәнем юк янымда.
**Кушымта.**

Сөяләм ялгыз каенга:
– Ял булыр, – дип, җаныма.
Серләремне кемгә сөйлим –
Сөйгәнем юк янымда.
**Кушымта.**

## Бер күрер өчен генә

Кайтыр идем яшьлегемә –
Төягем бишегенә,
Тәүге мәхәббәтне тагын
Бер тояр өчен генә.

**Кушымта:**
Эх, кайтырга яшьлегемә –
Ярымны сөяр идем.
– Син бит минем йөрәгемнең
Яртысы, – дияр идем.

Эх, кайтырга бер минутка –
Бер күрер өчен генә,
Беренче сөйгән ярымны
Бер сөяр өчен генә.

Кайтыр идем яшьлегемә
Чәчкәле май кичендә,
Чәчкәләрдән такыялар
Тик үрер өчен генә.
**Кушымта.**

Кайтыр идем бер мизгелгә
Яшьлегем нигезенә,
Яшьлек белән араларны
Тик өзмәс өчен генә.
**Кушымта.**

## Быргы моңы

**Балаларны яклау көненә арналган**

Борын-борын заманада
Калды безнең балачак,
Букча асып, борын тартып,
Быргы уйнап йөргән чак.
Борын-борын заманалар
Калды Кафтау артында,
Таудан-тауга канат җәеп
Очты хыял атым да.

Әкиятле бала чакка
Кайтыр идем шатланып,
Тау артындагы атымның
Канатына атланып.
Кайтып булмый бала чакка –

Ашкынуларым бушка,
Бала чактагы әкият
Ашмый икән тормышка.

Борын-борын заманага
Борылып карыйм гына,
Карлар яуган чәчләремне
Бары тик тарыйм гына.
Быргы моңы чакырса да
Борын-борын заманга,
Артта кала чакырымнар –
Кайтып булмый һаман да.

## Биек тау итәгендә

Аркабаш тавы башыннан
Туган авылым күренә,
Яр буендагы чыршылар
Биекләргә үреләә.

**Кушымта:**
И, авылым-авылкаем,
Ярата сине җаным,
Биек тауның итәгендә
Яралган кайнар каным.

Аркабаштау итәгенә
Сузылган туган авылым,
Туган якның ярларына
Кайтасы иде тагын.
**Кушымта.**

Аркабаш тавы башыннан
Карыйсы иде тагын

Биек тауның битләрендә
Калды бит бала чагым.
**Кушымта.**

– Аркабаш тавы, – димен дә,
Борылып артка карыйм,
Бала чагымны сагынып
Үткән елларны саныйм.
**Кушымта.**

## Яшимен уйларымда

Минем яшьлек истә калды
Агым-су буйларында,
Яшьлегемне искә алып
Яшимен уйларымда.
Яшьлегемнең агым суы
Ага туган ягымда,
Уйларымда яшьлегемә
Кайтам тагын-тагын да.

Тезелсә дә сәйлән кебек
Үткән гомер юлларым,
Урап-урап кире кайта
Яшьлегемә уйларым.
Уйларымның моң-зарлары
Кайта яшьлек таңына,
Чәчкәләрен койган яшем
Яшьлегемне сагына.

Безнең яшьлек үтеп китте –
Ерагайды аралар.
Зар-сагышлы уйлар белән
Еллар узып баралар.

Узып китсә дә яшьлегем –
Ерагайса да ара,
Хыялый уйларым һаман
Яшьлеккә таба чаба.

**Җиләкле җәй**

Кызлар җыя кызыл җиләк,
Кулларында туез чиләк,
Җиләкләре төшә тәгәрәп.
Беләзекле беләкләре,
Бизәк төшкән күнәкләре,
Күбәләкләр оча тирәләп.

Кызарып пешкән җир-җиләк,
Тезелгәннәр җирне бизәп,
Җәйге кояш сибә нурларын.
Җегәрле кыз җырлый-җырлый
Күнәгенә җиләк җыя,
Күбәләкләр тыңлый җырларын.

Каенлыкта каен җиләк,
Арасында җир җиләге,
Мәрхәмәтле Ходай бүләге.
Кызлар җыя сайлап-сайлап,
Кызыл җиләк төшә җайлап,
Мөлдерәмә тула чиләге.

Ходай биргән җиләкле җәй,
Җиләк белән бик тәмле чәй,
Табигатьнең чиксез бүләге.
Өстәлеңдә җиләк булса,
Өстәвенә кунак килсә,
Татлы балның юктыр кирәге.

## Кара мунча

Истә калган – бала чакта
Чабата үргәннәрем,
Тальян гармунда уйнарга
Мунчада өйрәнгәнем.
Кара мунча – бала чагым,
Кулымда тальян гармун.
Картайсам да истән чыкмый
Күңелемдә калган моң.

Хәтеремдә авылымның
Караңгы мунчалары,
Әтиемнең тау шуарга
Ясаган чаналары.
Кара мунча – бала чагым,
Кулымда тальян гармун.
Чәчләремә кар яуса да
Исләремнән чыкмый моң.

Хыялыма сеңеп калган
Кара мунча исләре.
Әле дә мин кулыма алам
Гармунымны кичләрен.
Кара мунча – бала чагым,
Кулымда тальян гармун.
Бала-чакның хыял моңы –
Онытылмый торган моң.

## Әтием чаналары

Урманнарга кереп күрсәм
Карама агачларын,
Искә алам әтиемнең
Кар ярган чаналарын.

Каен тешле, карамалы
Әтием чаналары.
Кар өстеннән төшләремдә
Әле дә шуам әле.

Хәтерлимен синең белән
Иркә бала чагымны.
Ий, әтием, искә алам
Бала-чаналарыңны.
Каен тешле бала-чана –
Бала чагымның яме.
Үсеп буема җитсәм дә –
Төшемдә күрәм әле.

Кара урманнарга кереп
Үсмер карама кисәм.
Әтиемнең чаналары
Гомергә чыкмый истән.
Җиңел чана «чал кашовка» –
Әтием чаналары.
Атлар җигеп төшләремдә
Һаман да чабам әле.

## Ялгызым кичәләре

Кышкы Ай йөзенә карап
Ялгыз үтә кичләрем,
Ялгыз аккош түгел идем,
Белмим, әллә нишләдем.
Ялгызым кичәләре, —
Газабын кичәм әле,
Килер вакыт — газиз җаным
Җәннәткә күчәр әле.

Ялгыз үткән кичләремнең
Газабы бетәр әле,
Җәннәттәге хур кызлары
Хурламый көтәр әле.

Ай да ялгыз минем кебек,
Йөзә зәңгәр диңгездә,
Икебезгә дә бер язмыш
Бер Ходай биргән безгә.

Хөрмәт итеп сине сорыйм:
-- Ий, Ходаем, бир түзем,
Ялгызлыкның газапларын
Беләсең бит син үзең.

Ялгызым кичәләре, —
Газабын кичәм әле,
Килер вакыт — газиз җаным
Җәннәткә күчәр әле.
Ялгыз үткән кичләремнең
Газабы бетәр әле,
Җәннәттәге хур кызлары
Хурламый көтәр әле.

**Ак чәчкәле яланда**

Кызарып кояш батканда,
Кызлар эштән кайтканда,
Ак кулъяулык төшеп калды
Ак чәчкәле яланда.
Алсуланып таң атканда,
Таң чыклары ятканда,
Кулъяулыкны табып алды,
Егет печән чапканда.

Җирдән алып тирен сөртте
Кояш нурын сипкәндә,
Чалгысына бәйләп куйды
Кызлар эшкә киткәндә.
Җилфер-җилфер килә яулык
Ак чәчкәле акланда,
Җиң сызганып печән чаба
Егет кояш батканда.
— Әй, серле кыз, кулъяулыгың
Югалттым дип акланма,
Егет күңеле сизеп алды
Кулъяулыгың тапканда.
Кыз егеткә сүзен бирде
Булган серен акларга,
Ай калыккач очрашырга
Ак чәчкәле акланда.

**Зинфирәкәй – зәңгәр күз**

Зәңгәр күзле Зинфирәнең
Иреннәре чияле.
Безнең авыл Сибәденең
Чибәрләрнең чибәре.
Кыңгырау чәчәге кебек
Аның серле күзләре,
Күңелемә шик тудыра
Ялындырган сүзләре.
Зинфирәкәй, зәңгәр күз,
Әйтмә миңа авыр сүз,
Килер кавышу көннәре —
Күпкә түздең, әзгә түз.
Зәңгәр күлмәгеңне киеп
Күл буена кил әле,

Күзгә кадәр көтәрмен, дип
Вәгъдәләрең бир әле.
Таң җилләре тибрәндерә
Күл өстендә көймәне,
Җиде ятларга ышанып
Туй күлмәген кимәле.

Зинфирәкәй, бик матурсың,
Минем өчен тугансың,
Шатлык белән тигез гомер
Кичерербез туйдан соң.

Зинфирәкәй, зәңгәр күз,
Әйтмә миңа авыр сүз,
Килер кавышу көннәре —
Күпкә түзден, әзгә түз.

## Ямансу

Йөрәгемә салкын карлар ява,
Таралдылар күңел моңнары,
Кыңгыраулар таккан пар ат булып
Үтеп китте гомер еллары.

Ак карларның төсе чәчләремдә,
Хисләр чумды тирән тынлыкка,
Нуры сүнде күңел кояшымның —
Кереп качты кара болытка.

Өзелделәр якты хыялларым,
Күңелләрем тулы ямансу,
Йөрәгемне били әрнү-сагыш,
Тынып калды сөю, ярату.

## Кил, назым

Ничә еллар сабыр гына
Сине көтәләр,
Гомер буе ялгызлыкта
Еллар үтәләр.
Сине көтеп гомер уза —
Иртә-кичәләр,
Узган еллар кызганмыйча
Мине сүтәләр.

И Гөлназым — таң йолдызым,
Юлдаш бул миңа,
Көтәм сине һәр ел саен
Язгы иртәдә.
Ник килмисең — юлларыңда
Юк бит киртәләр.
Кил, Гөлназым, кил яныма,
Назлап иркәлә.

## Килер әле бәхет көзләре

Аяз күктәй зәңгәр
Нурлы күзләреңә
Кемнең генә күзе төшмәде.
Күзләреңне күзләп,
Үз бәхетен эзләп
Өметләрен сузып өзмәде.
Кулларыңны сорап,
Изгелеккә юрап,
Кемнәр генә кулын сузмады.

Гомер буе эшләп,
Тулы бәхет эзләп,

Үтеп бара гомер елларың.
Кай вакытта утырып,
Күңелләрең тулып,
Сиздермичә безгә еладың.
Җыен, мәйданнарда,
Шатлык, бәйрәмнәрдә
Җырларыңны сузып җырладың.

Гомер елларында,
Тормыш юлларында
Чәчкәләрдән чәчкә өзмәдең.
Тик кемнедер сайлап,
Төпле акыл яулап,
Үзеңә син тиңдәш эзләдең.
Тыштан дөрләп янган,
Эче тулы ялган —
Андыйларны җаның түзмәде.

Һәр көн сабырлыкта,
Күңел ялгызлыкта
Гомер уза, диеп көймәле.
Гомер көзләрендә,
Кайнар йөрәгеңдә
Калыр әле бәхет эзләре.
Сүндермәле янган
Зәңгәр күзләреңне,
Килер әле бәхет көзләре.

## Резедалар

Җәйнең матур көне,
Резедалар гөле
Чәчкә аткан үрелеп кояшка.

Гомер юлын үтәм,
Хыялымда сүтәм,
Яшьлегемне алып юлдашка.

Резедалар өзеп,
Бизәр идем тезеп
Бергә үткән яшьлек эзләрен.
Әгәр эзләп тапсам,
Яшьлегемә кайтсам,
Ияр идем башым тезләнеп.

Резедалар кочып,
Барыр идем очып,
Яннарыңа барыр юл булса.
Яшьлегемнән эзләп
Сине табар идем,
Яшьлегемә кайтыр юл булса.

## Төй буйлары ник боек

**Төй буйлары бик тә боек,**
**Яшимен шуны тоеп,**
**Без киткәчтен елга ага**
**Сагыш-моң белән тулып.**

Төнбоеклы Төй буйлары,
Яшьлегем тугайлары,
Еллар аша ишетелә
Сайраган тургайлары.
Төй буйлары яшьлегемнең
Кызганычлы еллары,
Төрле якка таралдылар
Кызлары һәм уллары.

Ятим калды су буйлары —
Су буе камышлары,
Ишетелми кошларның да
Сайраган тавышлары.
Без булмагач сайрар кошлар
Сайрамыйлар тирәктә,
Үткәннәрнең моңы булып
Калды сагыш йөрәктә.

Төй буйлары яшел үлән,
Төнбоеклы агым су,
Төй буйлары тынып калды,
Сулары ага моңсу.
Онытылмый тугайлары,
Уйнап үскән ярлары,
Ахун авыл, Каюм, Истәк —
Туган якның аһ-зары.

**Кайда сез, якташларым?**

Туган ягымда тумаган
Үзенең «Такташлары»,
Шигырьләрем аша эзлим —
Кайда сез, якташларым?

Югалдылар авылдашлар...
Кайда газиз башлары?
Бәлки сезне көтәләрдер
Калган нигез ташлары.
Кайда минем якташларым...
Килми язган хатлары.
Кайсы илгә, кай җирләргә
Сезне язмыш ташлады.

Ярты гасыр вакыт үтте
Таралышып киткәнгә.
Ышанам: тормыш юлларын
Алар матур үткәнгә.
Сүрелми күңел учагым,
Күмерләре сүнсә дә.
Онытылмас җан дусларым,
Гомер янып бетсә дә.
Сөйләр идем дусларыма
Гомерем агышларын,
Кайда соң сез, якташларым —
Гомерлек сагышларым.
Туып үскән туган якны
Сез дә сагынасыздыр,
Минем кебек күз яшьләрен
Көндә тамызасыздыр.
Янып сүнгән йөрәкләрне
Тагын кабызасыздыр,
Кабат әйләнеп кайтырга
Канат кагынасыздыр.

**Төй буе авыллары**

Сихри, гүзәл Төй буйлары —
Бар иде авыллары,
Яшел хәтфә үзәннәре,
Борма-борма юллары.
Саф табигать почмагының
Таралды авыллары,
Читкә китеп югалдылар
Егетләре, кызлары.
Төй буе авыллары —
Үткән заман еллары,

Туган илсез калганнарның
Сагышлы зар-моңнары.
Кире борылып кайтырга
Бетте борма юллары,
Балкып торган ярларында
Сүнде янган утлары.
Ятим калды Төй буйлары —
Йөрәкләр әрнеп янды,
Табигатьнең бар җиһаны
Тирән йокыга талды.
Төй буе авыллары —
Йөрәгем янулары,
Газиз илем, туган җирем,
Авылсыз калулары.

* * *

Шул авылларның берсендә
Яшәде туганнарым,
Авыл бетте, юк туганнар —
Күккә иңде җаннары.
Читкә китеп сагышларда
Яшиләр калганнары.

## Исемнән чыкмый Истәк

Истәк авылы минем
Җанга якын җирем,
Бала чакның тәүге иртәсе.
Алсу таңнар аткан,
Хисләр ташып аккан
Истәлекле яшьлек иртәсе.

Саф һавасын сулап,
Тальян гармун уйнап,
Җырлап үткән яшел үзәннәр.

Җәйге айлы кичләр,
Тәүге кайнар хисләр,
Үзәкләрне айкап өзәләр.

Исләремдә һәрчак
Чатнап янган учак,
Яр буенда үскән балачак.
Онытылмый шул чак,
Йөгереп үткән сукмак,
Гомерем буе сузылып барачак.

Бетте авыл Истәк,
Үтте гомер читләп,
Туганнарым ия гүрләргә.
Әле бүген исән,
Иртәгәсен үлсәм,
Кемнәр килер мине җирләргә.

Газиз туган ягым,
Якын туганнарым
Сагындырып искә төшәләр.
Моңсу уйлар уйлап,
Ялгыз ямансулап,
Юксындырып еллар үтәләр.

## Түгәрәк күл

Күзге кебек түгәрәк күл
Төй буе тугаенда,
Безне тилмереп көтәдер
Газиз туган ягымда.
Түгәрәк күл, яшел тугай
Безнең яшьлек язлары,

Туган якның табигате
Кочагында назлады.
Түгәрәк күл буйларында
Төй буе болыннары,
Шунда туып, шунда уйнап
Үтте яшьлек еллары.

Төй буенда түгәрәк күл
Йөдәтә төшкә кереп,
Болындагы чәчкәләр дә
Безне көтәдер кебек.

Төнбоеклы күл буенда
Үсә зифа камышлар,
Туып үскән туган яктан
Аерылды язмышлар.
Аерылдык туган яктан,
Каерылды канатлар,
Узган гомер, язган язмыш,
Булмый аны кабатлап.

* * *

Йомшак кына искән таң җилләре
Тибрәндерә күлнең өсләрен,
Бер кайтасы иде туган якларыма
Әйтер өчен сагыну сүзләрен,
Бер киләсе иде яшьлек күлләренә,
Күрер өчен яшьлек эзләрен.

## **Бәлки безне искә алырлар**

Туган ягым ямьле,
Агым Төй буйлары,
Ятып эчтем тәмле суларын.
Тугайларда аунап,

Су буйларын буйлап,
Уйнап үскән якын дусларым.

Төй буйлары буйлап,
Гарасатлар дулап,
Килде безгә дәһшәт давыллар.
Авыр язмыш сулап,
Сабыйларча елап,
Чыгып киттек туган авылдан,
Давыллардан качып,
Төенчекләр асып,
Кайтмаска дип кире яңадан.

Яланаяк үскән
Яшел тугайларда
Сүнеп калды янган учаклар.
Ярларында үскән,
Урман буйлап үткән
Югалдылар безнең сукмаклар.

* * *

Чит якларга китеп,
Авыр еллар кичеп,
Яшәдек без гомер сагышта.
Тормыш шулай үтте,
Үзенекен итте —
Буйсындырды безне язмышка.
Кемдер күптән «китте»,
Гомер читләп үтте,
Үкендереп шушы язмышка.

Тормыш безне сүтте,
Гомер шулай үтте —

Кайталмадык туган якларга.
Озын еллар үтәр,
Җил-давыллар бетәр,
Аяз күктә сайрар тургайлар,
Килгән буын үсәр,
Ятып сулар эчәр
Без калдырган яшел тугайда.

Онытмаслар безне,
Без калдырган эзне,
Сукмакларны эзләп табарлар.
Урманнарны ярып,
Тигез юллар салып,
Яр буенда учак ягарлар.
Тамырларны табып,
Нигез ташын танып,
Бәлки безне искә алырлар.

## Кырык нәсыйхәт

**Изге язмалардан чүпләп, шигырь юлларына теркәлгән.**

1. Нәсыйхәткә тугры кеше
   Юлын югалтып калмас,
   Бу вәгазьне кире каккан —
   Тормыш сукмагын тапмас.

2. Нәсыйхәтне үз күрүче
   Белемне дә яратыр,
   Шелтә сүзен күралмаучы
   Яман эштә җан атыр.

3. Хак юлыннан тайпылучы
   Каты җәзасын алыр,

Шелтә сүзен кире каккан,
Һичшиксез, һәлак булыр.

4. Гадел кешенең сафлыгы
Тормыш юлын күрсәтер,
Мәкерле кеше хәйләсе
Үз бәхетен читләтер.

5. Акыллының зирәклеге
Үз юлын аңлавында,
Аңсызларның ахмаклыгы
Һәрчак үзе янында.

6. Ахмак кеше юлдан язып,
Үз юлына баз казыр,
Күңелендә Раббыга
Ачу хисе кузгатыр.

7. Акыл җыйган гадел кеше
Үз җанын да яратыр,
Акыл белән гамәл кылып,
Үзенә бәхет табыр.

8. Акыллылар бар бәладән
Читкә тайпылып калыр,
Тәҗрибәсез бәндә исә
Бәла утында яныр.

9. Зирәк кешенең өендә
Җиһаз — хәзинә булыр,
Ахмакларның бар белгәне
Байлыкны туздырудыр.

10. Ахмакны ашлыгы белән
Килегә салып төйсәң дә,
Ахмаклыгын аерып булмас
Кыздырылган утлы күмер
Түбәсенә өйсәң дә.

* * *

11. Тәкъва кеше күңелендә
Мәхәббәт хисе булыр,
Ә яманның ачы теле
Золым белән туелыр.

12. Тәкъва кешенең җимеше
Мәрхәмәт булып иңәр,
Зирәкле һәм саф җаннарны
Үзенә җәлеп итәр.

13. Абруйлы исем яулау
Мөлкәттән кадерлерәк,
Ихтирамга лаек булу
Алтыннан кыйммәтрәк.

14. Акыл җыеп зирәклеккә
Ирештем дип мактанма,
Гаепсезгә нахак ябып —
Гаепләнене аклама.

15. Таянма үз белдегеңә —
Аллаһыны юлдаш ит,
Мин акыл иясе димә —
Раббыны хөрмәт ит.

16. Үзбелдекле — гел үзенә
Кирәкне генә эзли,

Һәр акыллы чыганакка
Аның чыдамы түзми.

17. Раббыны хөрмәт иткән
Үзен хәвефсез тояр,
Явызлык та кагыла алмас --
Алла коймасын кояр.

18. Тугры юлдагы кешегә
Хәләл бәрәкәт явар,
Тиз баерга ашыгучы
Тиешле җәза алыр.

19. Нахак юл белән табылган
Икмәк тәмле тоелыр,
Әмма соңыннан авызың
Кара ком белән тулыр.

20. Ялган тел белән ирешкән
Хәзинә хәләл булмас,
Ялган сүзле ялган шаһит
Җәзасын алмый калмас.

21. Иманы нык шаһит кеше
Ялган сүзне сөйләмәс,
Ә ялганчы ләчтит сатып
Алдашудан җиләмәс.

22. Ялган чәчкән яман кеше
Бәлане урып алыр,
Һәм аның мәкер таягы
Тәмуг утында янар.

23. Мәкерле кеше юлында
Чәнечкеле куак бар,
Сукмагында саклап тора
Алла куйган тозаклар.

* * *

24. Юмарт кешенең байлыгы
Көн саен арта барыр,
Бирәү бик саран булса да
Фәкыйрь юлында калыр.

25. Ач күзлелек һәм саранлык -
Саранны һәлак итәр,
Чөнки аның комсызлыгы
Чамадан чыгып китәр.

26. Юмарт җанлы бай булыр,
Саран кеше сай булыр,
Байлык кына өмет иткән
Тигез юлда абыныр.

27. Фәкыйрьне читләп үтәрләр
Туганнары танымас,
Ул сөйләшеп аңлашырга
Аларны эзләп тапмас.

28. Фәкыйрь буласың килмәсә ,
Күп йокыга бирелмә,
Күзеңне ач, тиреңне түк —
Бер телемгә тилмермә.

* * *

29. Әдәпсезнең үткен теле
Кылычтай җанны телә,

Ә акыллы кеше сүзе
Жаныңа жылы өрә.

30. Телен тыйган — жанын саклар,
Тыйнаклык аны яклар,
Авыз ерып лыгырдаучы
Яман гамәлен аклар.

31. Иреннәрен тешләп-тешләп
Явыз гамәлен эшләр,
Гомер шәме дөм-караңгы
Бушлыкта пыскып сүнәр.

32. Явызлар гөнаһка батып
Һичшиксез дөмегерләр,
Үз-үзләрен һәлак итеп
Гүргә барып керерләр.

33. Явыз кеше – вакытында
Тиешле җәза алсын,
Аяк асты — баскан җире
Ут булып дөрләп янсын.

34. Ат өчен — камчы кирәк,
Ишәккә йөгән кирәк,
Явызларга йөгән түгел —
Аңа авызлык кирәк.

35. Яман кешедән көнләшмә,
Аның белән берләшмә,
Чөнки алар золым эзли —
Фәкать яманлык чәчә.

36. Башкаларга баз казыган —
Үзе егылып төшәр,
Ташны үргә тәгәрәтсәң —
Кире башыңа төшәр.

37. Күптән утыртып куелган
Ызан ташын күчермә,
Болай да фәкыйрь кешенең
Җиренә басып кермә.

38. Дошман кешенең авызы -
Ягымлы нәрсә сөйли,
Күңелендә мәкер ята,
Йөрәге сине сөйми.

39. Әгәр дошманың ач булса,
Икмәгеңне бүлеп бир,
Игелекле эшең белән
Мәкер корган күңеленә
Салырсың утлы күмер.

40. Теләкләрем, ниятләрем
Мул агымлы су кебек,
Акыллылар чиләкләрен
Алыр чумырып, өеп.

## Җилкуар

Җил көньякка һәм төньякка
Карап хәрәкәт итә,
Үз юлыннан бөтерелеп
Әйләнеп үтеп китә.
Һәр көн саен үзгәрмичә
Кич була да таң ата.

Бу дөньяда бар нәрсә дә
Кире әйләнеп кайта.

Барлык елга сулары да
Агып диңгезгә коя,
Әмма диңгез тулып ташмый —
Сулар башланган җиренә
Кабат кайта да куя.
Кояш чыга, Ай да калка —
Һәр нәрсәнең үз юлы,
Дөньядагы бөтен нәрсә
Мәшәкать белән тулы.

Ыруг-нәсел килә, китә —
Дөнья мәңге торачак,
Моңа чаклы булган нәрсә
Моннан соң да булачак.
Туфрактан яратылган
Туфракка кайтачак,
Сарыф иткән көчләрегез
Бар да юкка чыгачак.

Фани дөнья мәшәкате
Бушка җил куу гына,
Тырыш шөгыль-хезмәтеңнең
Җилгә очуы гына.
Анадан туган шикелле
Кеше шәрә калачак,
Ахырында барыбыз да
Бер урынга барачак.

Авыр хезмәт җимешенә
Кемдер хуҗа булачак,

Әллә ялкау, әллә зирәк,
Әллә булыр бер ахмак.
Ахыр чиктә бу дөньяда
Мәңгелеккә калмыйбыз,
Үзебездән көчлерәккә
Каршы тора алмыйбыз.

Киләчәкнең ни буласын
Төптән уйлап белегез,
Дөнья диеп җил кумагыз,
Уйнагыз да көлегез.
Минем сезгә үгетем шул:
Аң белән эш итегез.
Бу дөньяның кагыйдәсен
Аңлап гомер итегез.

## Уйныймын гармунымны

Аламын да гармунымны,
Уйныйм урам көйләрен,
Яшьлегемдә яңгыраткан
Кичке аулак өйләрен.
Искә алам яшьлектәге
Бер сөйгән гүзәлемне,
Иске гармун, иске көйләр,
Өзәләр үзәгемне.

Уйный гармун «Шахта» көен,
Сайрый «Сарман» моңнарын.
Хыялымда зәңгәр таудан
Болгый кемдер кулларын.
Зәңгәр күлмәк, ак кулъяулык
Ак томан аша күрәм,

Мәхәббәтле яшьлегемнән
Хыял гөлләре үрәм.

Уйный гармун яшьлегемнең
Ал таң аткан иртәсен,
Шул бәхетле минутларның
Ай калыккан кичәсен.
Уяндырып сөю хисен
Уйный яшьлек көйләрен,
Йөрәгемдә ярсу сагыш,
Уйларымда сөйгәнем.

Бармагым уйный да уйный —
Баса эзләп телләрен,
Зәңгәр томаннар артыннан
Таба яшьлек эзләрен.
Бармакларыма бәйләнгән
Моңнарым, сагышларым,
Яшьлегемә кире кайтып
Бер уйнар идем тагын.

## Иске гармун

Өй түрендә иске гармун
Санамый үткән елын,
Түкми-чәчми һаман саклый
Исендә калган моңын.
Тальян гармун — үткән заман,
Уйный ул әле һаман,
Аның тавышлары тарта
Һаман яшьлеккә табан.

Уятып яшьлек хисләрен
Уйный әле кичләрен,

Уйный үзәкне өздереп —
Ача йөрәк серләрен.
Иске гармун искә алып
Уйный моңлы хисләрен,
Яңгырата авыл кичен
Биреп соңгы көчләрен.

Уйный әле иске гармун,
Күрекләре тузса да,
Уйный йөрәкне яндырып,
Гомерләре узса да.
Тальян гармун — узган гомер,
Янып сүрелгән күмер,
Ишетсәм аның тавышын
Тагын кабына күңел.

## Дәртле гармун

Яратам мин үткән заман
Саратов гармуннарын,
Урамнардан уйнап узган
Сайратып зар-моңнарын.
Аның моңы күрегендә,
Дәрте көмеш телендә,
Кыңгыраулы көмеш чыңы
Чыңлый күңел түрендә.
Яңгырый дәртле көйләре
Үткән заман күгендә,
Хыял дөньясына чумып,
Тыңлар идем бүген дә.

Уйнап узды яшьлегемнән
Саратов гармуннары,

Хыялымда йолдыз булып
Яна сагыш-моңнары.
Пар кыңгырау, чиккән яулык
Аның каешларында,
Уйный кояш чыгышында —
Чыңлый баешларында.
Уяна дәрт күңелләрдә
Гармун тавышларына,
Үткән заман — дәртле гармун —
Янам сагышларымда.

**Килми ташлап китәсе**

Син, гармуным — чын юлдашым,
Чыңлыйсың кулларымда,
Күңелләремне бизисең
Ялгыз минутларымда.

Бармакларым моңнар сибә
Гармуным телләрендә.
Әйтерсең лә, сулар сибә
Мәхәббәт гөлләренә.

Уйный бармак, телен аңлап,
Кулымда көмеш балдак,
Көмеш телле гармун белән
Йөрибез икәү парлап.

Гармун белән горур атлап,
Килде гомер көзләре,
Мәхәббәт сукмакларыннан
Эзлим бәхет эзләрен.

Авыл урамнары буйлап
Үтте яшьлек иртәсе.
Аның хисе ташып ага —
Килми ташлап китәсе.

## Гармунчы дусларыма

Сез, дусларым, гармуннарны
Кулыгыздан куймыйсыз,
Ялкын булып, төрле көйләр
Ял итмичә уйныйсыз.

**Кушымта:**
Гармун басмаларын бизи
Елтыр балдакларыгыз.
Көмеш телле гармун уйный
Алтын бармакларыгыз.
Каршыгызда биеп тора
Биюче кызларыгыз,
Әй, дусларым, гармунчылар,
Таламы кулларыгыз?

Биючеләр абынмыйлар,
Бигрәк оста уйныйсыз,
Уйныйсыз кирәген әйтеп,
Ялындырып тормыйсыз.
**Кушымта.**

Алтын балдак, талмас бармак,
Маладис кулларыгыз,
Уйнап, көлеп, җырлап үтсен
Киләсе елларыгыз.
**Кушымта:**
Гармун басмаларын бизи
Елтыр балдакларыгыз.

Көмеш телле гармун уйный
Алтын бармакларыгыз.
Каршыгызда биеп тора
Биюче кызларыгыз,
Әй, дусларым, гармунчылар,
Талмасын кулларыгыз.

## Очты тәкә коега

Язар өчен бер вакыйга
Каләм очлыйм кулымда,
Бер кайгысыз бала чакның
Хатирәсе турында.
Балачак ул кабатланмас
Шаян гомер иртәсе,
Ни кылсаң да шул килешә —
Юк бит аның киртәсе.
Бик тә кызык бер хатирә
Килә язып китәсе.
Шау-гөр килгән бала чакның
Уникенче язында,
Туган яктан урман аша
Күчтек урыс ягына.
Урыс ягы урыс инде —
Түгел ул туган җирең,
Телләрен дә аңламыйча
Авызны ачып йөрим.
Сөйләшү дә чама гына —
Ипилек, тозлык кына,
Ачу килсә, аңлатырга
Төйним йодырык кына.
Күрше тирәсе дә урыс,
Бары да эшчән, бик тырыш,

Ләкин йодырыкны күргәч,
Сүгенәләр бик кырыс.
Анысын тиз чалып алам —
Значит, миңа каюк,
Татарча да, урысча да
Әллә ни аерма юк.
Менә шулай яши торгач,
Эшне тәртипкә куйгач,
Малайлар да йомшадылар
Йодырык тәмен тойгач,
Әллә шунысы килеште —
Сугыш чукмары булгач.
Уйныйбыз да көлешәбез,
Көн саен көрешәбез,
Уен болынына чыгып,
Көч сынап көрәшәбез.
Кай вакытта, кызып китеп,
Пыр тузып сугышабыз,
Иртәгәсен сүзсез генә
Кул биреп дуслашабыз.
Кояш чыга, җир әйләнә,
Ай, кояшка бәйләнә.
Бала-чага дөньясы да
Шул чамада әйләнә.
Бердәнбер көн иртән торып
Кое янына киләм,
Суын алып чәй эчәргә —
Гади бер ният беләп.
Якында йөри бер тәкә —
Чүпләнә яшел үлән,
Сөзешергә бик ярата —
Мин аны күптән беләм.

Әмма ул мине сөзәлми —
Күккә сикереп калам,
Бот арамнан үтеп китә —
Артыннан көлеп калам
(Ул бит аңгыра. Баран).
Аның хуҗасы да күрше,
Максим дигән бер кеше.
Мин әзерәк шөрлимен дә —
Ул бит безнең тимерче.
Көне-төне тимер чүки,
Шуңа куллары көчле.
Аның кулы «утыз кадак» —
Дага бөгәргә ярый,
Йодырыгын бер күрсәтсә,
Тәкә дә аны аңлый.
Менә тагын шушы тәкә
Мине сөзәргә уйлый,
Адым саен сөзешмәсә,
Аның «тамагы туймый».
Мин дә алай куркак түгел —
Тәкәне читкә кудым,
Арттан килеп сөзмәсен, дип,
Йодырыкларымны төйнәп,
Алдымны борып куйдым.
Карап торам: бу тибенә,
Артка таба чигенә.
Эх, мин әйтәм, таяк булса,
Бирер идем биленә.
Бер ун адым чигенде дә,
Таптанды күзгә карап,
Борма мөгезләрен текәп
Ташланды миңа таба.

Мин шулай ук — элеккечә
Калдым үргә сикереп.
Арттагы кое бурасын
Сөзде туры китереп.
Чынлап әйтәм — шушы мәлне
Үч юк иде уемда —
Ә дигәнче мәтәлчекләп,
Очты тәкә коега.
(Кеше ышанмас хатирәне
Саклыйм гомерем буена).
Мин дә шулай ышанмыйча
Карыйм тирән коега.
Теге тәкә су эчендә
Йөзгән кебек тоела.
Бу бит әле исән, диеп,
Тирә-якка карыймын,
Бакчасында йөри берәү —
Ул урысны таныймын.
«Быстро ходи здесь», — дип
Кычкырам шул урыска,
(Кайвакытта мин аларга
Керә идем йомышка).
Кырыс урыс мескен булды
Куркып минем тавышка.
Бик тиз генә йөгереп килде —
Кулына балта тоткан,
Әйтерсең лә, табаныннан
Бөтен котлары купкан.
Эшнең нәрсәдә икәнен
Сүзсез аңлатып биргәч,
Тәкә коеда йөзгәнен
Үз күзе белән күргәч,

Өстен салып ташлады да
Сүгенергә башлады.
Теге урыс мине тирги,
Үзе тәмәке көйри,
Төкереген чәчә-чәчә,
Аңламыйм, нидер сөйли...
Ах ты, суккин татар малай —
Без тебя была тоска,
Как ты здесь появился —
От тебя болит башка.
Урыс авызына карап,
Бирдем мин аңа җавап; —
Правильно ты говориш —
Хорошо эшли башка,
Мин тәкәдән сөздермәдем —
Төшеп китте ул аска.
Килеп чыкты Максим — хуҗа –
Йөгерә яланаяк.
Тимерлектә күмер тарткан —
Кулында кисәү таяк,
Күзләре дә бик акайган —
Мин әйтәм, эшләр харап.
Йөгереп килде әти (мәрхүм) –
Тоткан озын дилбегә,
Кое эченә төшәргә
Указ бирде тиз генә.
Ата сүзе — Алла сүзе —
Мин аңа буйсынамын,
Суга түгел, ут эченә
Керергә дә ризамын.
Тимер кыршау, зур бидрә,
Кулда — каеш дилбегә,

«Көмеш» чылбырга тотынып
Кереп бастым төбенә,
Әти белән ике урыс —
Берсе һаман сүгенә,
Чыгыр белән әйләндереп,
Бик тиз генә төшерделәр,
Тирән кое төбенә.
Текәп карыймын күземне —
Тәкә башы күренә,
Кое суын эчә-эчә
Бака кебек күбенә,
Бата-чума йөзә мәхлук —
Күзе аклы-каралы,
Баткан чакта күзгә карый —
Жәлләдем бичараны.
Күп уйламый, бер кул белән
Эләктердем чәкәнен,
Дилбегәне бәйләп куйдым
Мөгезенә тәкәнең.
Өстәгеләр иң беренче
Мине тартып алдылар,
Минем арттан тәкәне дә
Алып җиргә салдылар.
Тәкә исән, мин шатланам,
Коткардым, дип мактанам,
Минем монда гаеп юк дип,
Урысларга акланам.
Тәкә хуҗасы килде дә,
Әтигә болай диде: —
Ну что, бабай, реж давай,
Пока ведь баран живой.

Кичектерми генә әти
Тәкәне суеп бирде,
Теге Максим чын күңелдән
Тәкә башын һәм тиресен
Әтигә бушка бирде,
Твой малай больно хорош —
Тун тегеп кидер, диде.

**Көтәбез Яңа елны**

Хәзер Яңа ел яңача —
Элекке кебек түгел.
Тагын килеп җитә, диеп,
Көрсенеп көтә күңел.

Телевизор кабызабыз,
Бер чәкине ачабыз.
Ил түрәсе вәгазь сөйли —
Үрә торып басабыз.
Ил башлыгы Илне мактый,
Караны аклап сөйли,
Ятлап алган иске җырын
Быел яңартып көйли.
Әмма иртән хак артасын
Бездән сер итеп саклый,
Әлбәттә, ул бу турыда
Сөйләргә сүзен тапмый.

Иртәгәсен алсуланып
Яңа ел таңы ата,
Төн чыкканчы йон чыккандай,
Ил буенча хак арта.
Әллә инде Кыш бабабыз,

Бүләк капчыгына төяп,
Төне буе йокламыйча
Яңа хаклар тарата.

Торып базарга барабыз,
Хәйран хәлгә калабыз,
Былтыргы хакларны эзләп,
Ары-бире чабабыз.
Кая гына йөгерсәк тә,
Яңа хаклар күрәбез,
Яңа елы белән бергә
Түрәләрне сүгәбез.

Убырлар иртә уяна —
Без торганчы торганнар,
Яңа елны тәбрикләп,
Убыр хакын куйганнар.
Эчебездә бүре улый —
Кеше бит ялап туймый,
Бертуктаусыз «Кара песи»
Җаннарны үртәп тырный.

Байлар, әлбәттә, сөенеп,
Кесәләрен сүтәләр,
Алыштырып киңрәккә,
Өр-яңадан тегәләр.
Яңа елда — яңа байлар
Мул гына килем кертә,
Ә фәкыйрьләр түрәләрдән
Яңадан мутлык көтә.

Ак бәйрәм кичәсе, Кара —
Алыпсатарлар төне,

Болай да фәкыйрь кешене
Акыртып талау көне.
Бу байларның бирәр вакыт
Тыгылыр микән өне?

ЖКХдан кәгазь килә,
Күзләр маңгайга менә.
Яңа бәяләргә карап,
Чәчебез үрә тора.
Ә түрәләр, безне алдап,
Үзенә түбә кора.

Ап-ак карлы кыш бәйрәме
Кара көнгә әйләнде.
Арттан калмый «кара сакал» -
Илебезгә бәйләнде.
Кара йөзләр, комсыз күзләр
Бу көнне күздә тота,
Ак бәйрәмгә кара ягып,
Караклар казна ота.

Кая карый баш түрәләр,
Кая барабыз икән,
Әллә моны үзләре дә
Белми-аңламый микән?

**Ак чәчлеләр**

Ак чәчлеләр — алар
Зирәк Аксакаллар,
Ак юл салып алдан баралар.
Гомер юлын үткән,
Төшмәгәннәр күктән —
Ак бәхетсез үскән балалар.

Алар үскән еллар,
Ак чәчкәсез юллар,
Йөрәкләре тулы яралар.
Кара язмыш яулап,
Кайгыларда кайнап,
Ак юл ярып тугры баралар.

Ак чәчләләр — алар
Иген чәчкән куллар,
Тук башаклы иркен далалар.
Эштә җанын аткан,
Дөнья малын тапкан,
Ак күңелле ата-аналар.

Ак чәчләләр — алар
Мәңге изге җаннар,
Янар чәчәк булып калалар.
Тырыш хезмәт көчен
Сезгә биргән өчен,
Хөрмәт итең, газиз балалар.

## Кем сагынмый туган якларны

Газиз туган ягым,
Язам әле тагын —
Кем сагынмый туган якларын.
Таң җилләре исеп,
Ал нурларын сирпеп,
Алсуланып таңнар атканын.
Таң кояшы чыгып,
Җирне чагылдырып,
Таң чыклары җиргә ятканын.

Кем сагынмый тагын,
Уйнап-үскән чагын —
Бер кайгысыз бала чакларын.
Болыннарны гизеп,
Чәчкәләрен өзеп,
Күбәләкләр куган чакларын,
Бит очларын уып,
Чаналарда шуып,
Шул ваемсыз сабый чакларын.

Кем уятмый икән
Яшьлек хәтирәсен —
Таң калырлык яшьлек иртәсен.
Такыялар үреп,
Бүләк итеп биреп,
Иркәләгән тәүге иркәсен.
Йөрәк ярсып типкән,
Ярын сөеп үпкән,
Сокланырлык сөю кичәсен.

Кем сагынмый илен,
Газиз туган җирен —
Болыннарда чәчкә атканын,
Кулларына алып,
Чалгыларны янап,
Шул болында печән чапканын,
Җиргә ятып аунап,
Чәчкәләрне сайлап,
Җир җиләген җыеп кайтканын.

Кем сагынмый тагын,
Яшьли сөйгән ярын,
Искә алмый яшьлек язларын.

Ил сафына басып,
Сакта мылтык асып,
Саф күңелдән хатлар язганын.
Кем йөретми икән,
Саклап йөрәгендә
Истәлекле солдат хатларын.

Әгәр уйлый калсаң,
Йөрәгеңә алсаң —
Сагындырмый тормыш кемнәрне.
Чын күңелдән янсаң,
Әгәр саный калсаң,
Сагышларда үткән көннәрне,
Җирдә янып-көеп,
Җилгә башын иеп,
Шиңәр иде чәчкә гөлләре.

**Билгесез сабыйга**

Артта калды еллар,
Ялгыз үткән юллар,
Оныкларым үсте буйларга.
Ак күлмәгем киеп,
Ак башымны иеп,
Ялгыз йөрим сабан туйларда.
Еракларда калган,
Гүя, бер сабыйны
Гомерем буе саклыйм уйларда.

Гомер ялгыш үтте,
Язмыш шулай итте,
Кире какты сузган кулымны.
Әгәр исән булса,
Барлыгымны белсә,

Табыр иде эзләп юлымны.
Ана күңеле — бала,
Баланыкы — дала —
Гафу итәм газиз улымны.

* * *

Сикәлтәле, катмар озын тормыш юлын
Җиңел түгел тигез үтәргә.
Үкенечләр кала гомер елларының
Йомгакларын кире сүткәндә.

## Асбест каласы

Киң Уралның уртасында
Асбест дигән бер кала,
Яшьлегемнең бер өлеше
Уралган шул калага.
Ул, әлбәттә, бик зур түгел —
Уртача гына кала,
Ә шулай да йөрәгемдә
Калды сагышлы яра.

Фабрика торбалары
Күтәрелгән һавага,
Халык телендә ул кала
Алтын диеп атала.
Аның мәгъдән* хәзинәсе
Бар дөньяга тарала,
Бик күп илләр сатулашмый
Алтынга сатып ала.

Анда чыккан асыл ташлар
Чит илләргә юл ала,
Хәтта патша кызлары да
Муенса итеп тага.

Искә алам шул каланы —
Төшләремдә чуала,
Анда калган яшьлек хисе —
Хисләремдә уяна.

Аерылдым шул каладан —
Ерагайды аралар,
Әкерен генә сиздермичә
Еллар үтеп баралар.
Еллар белән гомер уза —
Буйга үсте балалар,
Ә йөрәктә сыкрап кына
Сызлый сагыш-яралар.

* мәгъдән — шахта: җир асты байлыклары.

## Олы-Елга – Базанчат

Туган авылым Олы-Елга —
Ике чакырым Базанчат,
Ике авыл арасыннан
Үтте минем балачак.
Олы-Елга — Базанчат,
Ике авыл чатлыгында
Калды безнең балачак,
Гомер дигән олы юлдан
Безне озатып барачак.

Базанчат авылы күркәм,
Урамы яшел чирәм,
Туган җирем булмаса да,
Мин аны якын күрәм.

Булмаса да туган затым,
Сиңа кайтам, Базанчат,

Өч туганым синдә калды —
Мәңгелеккә ятачак.

Кайткан саен балаң итеп
Кочагыңа аласың,
Илһам биреп юл чатында
Мине озатып каласың.

Базанчат юлына сөйлим
Сагышлы сүзләремне,
Балачакларымда калган
Саклыйсың эзләремне.

Синең юлларыңнан үтте
Гомеремнең иртәсе,
Күпме еллар үтсәләр дә
Сүрелми хатирәсе.

Бала чагым торып калды
Ике авыл чатында,
Берсе — елга буйларында,
Берсе — Базан чатында.
Олы-Елга — Базанчат,
Ике авыл чатлыгында
Калды безнең балачак,
Гомер дигән олы юлдан
Безне озатып барачак.

## Гәрҗе

Гәрҗе авылы — кара урман,
Урманчылар бик уңган,
Искитәрлек хөр табигать
Кочагына сыенган.

Хәзинәсе — җиләк-җимеш,
Шомырт, миләш һәм балан,
Шул табигать гүзәллеген
Һаман да искә алам.

Бала чакның бер өлеше
Үтте урыс ягында,
Хәерчелек һәм ятимлек
Бүлде өч-дүрт авылга.
Гәрҗе авылы да шушы
Язмышыма кагыла.
Урман кисеп буйга үстем
Бала гына чагымда.

Урман җиләкләрен җыйдым
Җиде юлның чатында,
Тимер юл буена төшеп,
Стаканлап сатарга.
Туганнарым урман кисте
Юлга шпал салырга,
Җиләк сатып акча җыйдым
Күлмәк-ыштан алырга.

Минем өчен Гәрҗе авылы
Үз туган җирем кебек,
Гомерем буе хөрмәт итеп,
Яшимен төштә күреп.
Яшермимен хисләремне,
Яраттым мин Гәрҗене.
Урман бетте, авыл да юк —
Калды йөрәк әрнүе.

**Фаҗига. 1942 ел**

Илдә каты сугыш бара,
Туплар ата, җир яна.
Өстәвенә, авыл буйлап
Яман чир атлап бара.
Тиф чире ул — үлем чире,
Юк аңардан бер чара.
Урам буйлап бер-бер артлы
Мәетләр торып кала.
Дөнья куйды карты-яше,
Вафат булды аналар.
Кот очарлык фаҗигале
Булды безнең замана.

Урак өсте — кайнар һава,
Яңгырдай кайгы ява.
Әнисеннән ятим калган —
Кайгыдан елый бала.
Кара кәгазь алган ана —
Кайгы утында яна,
Кадерле газиз баласын
Кабергә илтеп сала.
Ул түгелгән күз яшьләре
Елгалар булып ага,
Ул кайгыдан араларга
Дарулар юк анага.

Йөрәкләрнең яралары
Җуелмый — мәңге кала.
Кайгыларны салып булмый
Дөрләп аккан дәрьяга.

Фаҗигале язмыш белән
Гомер елларым ага.
Кабат әйләнеп афәтләр
Килмәсен бу дөньяга.

* * *

Олы-Елга суы агар,
Йолдыздай балкып янар.
Авылымның фаҗигасе
Тарих битендә калыр.

**Замана**

Безнең гомер уяу булды —
Утырмадык ояда,
Кыя кошы — бөркет булып
Мендек биек кыяга.
Яшьлегебез чәчкә атты —
Калдырмадык заяга,
Йөгәнсез ат, очар канат —
Без яшәгән замана.

Үтте гомер, сүнми күңел —
Очар төсле канатлар,
Җиталмый күңел артыннан –
Артта кала аяклар.
Җиңел чана, җитез атлар,
Җиз кыңгырау дугада —
Кабатланмас эз калдырып
Узды безнең замана.

* * *

Авызлыклап йөгән киде
Без менгән тулпар атлар.

Онытылды туганлыклар —
Танымый туган — затлар.
Килгән замана җиленә
Сынды җилфер канатлар,
Җиргә тапталган намусны,
Белмим: аны кем аклар.

Канатсызларны калдырып
Бу дөнья кая бара,
Канатлылар күккә оча —
Аралар ерагая.
Бу заманага зарланып
Гомер үтә заяга.
Күтәрелеп очып булмый —
Утырабыз ояда.

## Чыганагым

Чыганагым — кара урман,
Куе кара чыршылар.
Зифа буйлы җилфер каен —
Җил искәндә "Җырчылар».

**Кушымта:**
Туган ягым, чыганагым,
Тәүге сулышым,
Төй буйлары тугаенда
Калды чыгышым.

Чыганагым — тулпар атлар,
Чаптар аяк колыннар.
Корыч чалгы, чапкан печән,
Чәчкә аткан болыннар.

**Кушымта.**

Чыганагым — Аскын ягы,
Асыл чишмә агышы.
Тумышымның асыл ташы,
Ашкын йөрәк сагышы.

**Кушымта:**

## Гомер юлым

Бала чакларымнан алып, бал кортыдай,
Болын чәчкәләрен яраттым.
Чәчләремнең төсе сыман аккош булып,
Җилпендем мин җирдә — канатсыз.

Үткән гомер юлым актан булмаса да,
Намусымны таптан сакладым.
Барган тормыш юлым такыр булмаса да,
Тайпылмыйча алга атладым.

Мактанырлык түгел үткән гомер юлым —
Манылмаган сары алтынга.
Әмма алган юлым, булды сабырлыгым —
Сабыр булдым Алла хакына.

Үткән гомер юлым — тырыш хезмәт юлы,
Ике кулым саклый исендә.
Үзем өчен генә түгел, хезмәт көчем,
Туккән тирем Илем өчен дә.

Хәләл күкрәк көчем эштә өзелсә дә,
«Озын» акча «көрәп» алмадым.
Хәрам мул-байлыкка хуҗа булмасам да,
Кирәгемә мохтаҗ булмадым.

Тормышымның аты арып атлаганда
Башкаларга йөгем өймәдем.

Өлеш дигән көмеш алларыма төшсә,
Алтынны да кирәк димәдем.

Үтә матур түгел үткән гомер юлым,
Әмма үкенмимен үткәнгә.
Тормыш шаукымнары аша горур атлап,
Шул яшемә килеп җиткәнгә.

**Кабык бишек**

Өй түрендә элгән сиртмә,
Беркетелгән матчага.
Сиртмә элмә агачыннан,
Алынмаган акчага.
Очына бер кадак кагып,
Эленгән кабык бишек,
Мендәре юк, төбе тишек,
Тирбәлә, белмим, ничек.

Кабык бишектә утыра
Кабак башлы бер бала,
Тошы да юк, теше дә юк,
Быел туган дөньяга.
Пешмәгән аш — корсагы ач,
Сөте дә юк имәсе,
Ишекне ачып кына куеп,
«Кайтып киткән" әнкәсе.

Елый бала, суза кулын —
Йод(ы)рыкка юана,
Ни икәнен сүзсез аңлый —
Түгел бала дивана.
Тынып калды өмет өзеп,
Утыра бала түзеп.

Берәү чәйнәп ипи бирде
Үз авызыннан өзеп.
«Әти» диеп теле чыкты,
Еламый үксеп-үксеп.
Кабык бишегеннән төшеп,
Җитте буена үсеп.

## Кара чыршы урманы

Туган ягым — кара урман,
Кара чыршы үскәнгә.
Карагайсыз кара урман
Мәңге калды исләрдә.
Кара чыршы урманында
Карагай юк кисәргә.
Туган яклар искә төшә
Карлар яуган кичләрдә.
Кар бураннары шикелле,
Ярсый кышкы хисләрем.
Карашларым сабыр иде,
Белмим, әллә нишләдем.

Кара җиргә кар яуганда
Карыйм туган ягыма.
Кара чыршы, кара урман
Якын, җылы җаныма.
Кышкы урман, кара чыршы,
Үткән чана юлларым,
Шул юлларга чакыралар
Урман кискән кулларым.
Кара урман, яшел чыршы...
Узган яшьлек елларым.
Үткәннәргә алып кайта
Кышкы озын уйларым.

Бер моңлы җыр булып калды
Кара чыршы урманы.
Күңелемдә урын алып,
Балкый урман нурлары.

Кара чыршы урманында
Йөрим төнге төшләрдә.
Йөрәгемнең тибешенә,
Белмим, көндез нишләргә.
Ак күлмәкле кышкы урман
Исемә төшә көн дә.
«Ак юрганы» җылы бирә
Күңелем өшегәндә.

**Калган эшкә кар ява**

Алсуланып таң атканда
Таң кояшына кара,
Яшьлегеңнең ал таңында
Бушка алданып калма.
Гомерләр артта калса да,
Яшең бит алга бара,
Яратканда яратып кал —
Калган эшкә кар ява.

Очырма бәхет кошыңны —
Ятып калма, атып кал,
Гомер үтәр, ләкин булмас
Капкан саен татлы бал.
Бер генә килгән гомернең
Ямен-тәмен татып кал,
Икеләнеп торып калма,
Иркәләнеп, сөеп кал.

Кызган чакта тимереңне
Суытмыйча сугып кал.
Кыз яратса, күпкә сузма,
Соңламыйча килеп ал.
Гомер барда кадерен бел,
Сөеп яшә дөньяда.
Сөелгәндә сөенеп кал —
Калган эшкә кар ява.

Сөйгән ярыңны калдырып,
Сөю утында янма,
Сөелеп, сөйгән ярыңны
Көю утына салма.
Читтән эзләмә бәхетне,
Үз ярыңнан читләнмә,
Башкаларның ташлап киткән
Чүп-чарыннан чүпләнмә.

Калсаң ялгызлар ярында,
Каерылса канатың,
Бөгелмә кара кайгыга —
Тагын килер ярату.
Бүген эзлә үз ярыңны,
Үтмәсен гомер зая.
Кичектермә, соңга калма —
Калган эшкә кар ява.

## Килер әле язларым

Тагын бер ел үтеп, гомер язым килде,
Язлар бит ул күңел бәйрәме.
Язым белән бергә узган яшьлегем дә
Килер төсле кире әйләнеп.

Тәрәз төпләрендә гөлләр чәчкә атты —
Назланалар язгы кояшка.
Үрмә гөлләр булып өмет белән тулып
Үреләмен мин дә кояшка.

Гомер-язмышыма яңа язлар теләп,
Чәчкәләрнең өзәм назларын.
Ходай гомер бирсә, янар чәчәк булып,
Килер әле өмет-язларым.

## Үз юлыңнан атладың

**Ачу белән караганга,**
**Каләм сүзем ачырак.**
**Көлемсери карашларың —**
**Кәрәз балдан татлырак.**

Хөрмәтемне кабул итеп,
Чын күңелдән алмадың.
Ачык чыраеңны бозып,
Ачуланып карадың.
Кара көйгән йөзең белән
Күземә карадың да,
Керфекләрең сөңге итеп
Йөрәгемә кададың.

Алуын-алдың да, иркәм,
Күңелем бүләгемне,
Салкын карашларың белән
Туңдырдың йөрәгемне.
Кире кагуын какмадың,
Гаделлекне сакладың,
Акыл-зиһен гадәтләрен
Бер гаепсез акладың.

Гаделлек бизмәнен корып,
Гаделсезлек кылмадың,
Йөрәк тамырын буарлык
Әмма тарткан кылларың.
Ләкин йөрәгем эрерлек
Җылы сүзләр тапмадың,
Күз нурларыңны сүндереп,
Үз юлыңнан атладың.

## Ике ятим

**Балачак дустым Камил истәлегенә багышлыйм.**

Синең гомер юлың бик тә кыска булды,
Күптән юксың безнең арада.
Гомер кояшыңның якты нуры, сүнеп,
Батты кара-кучкыл дәрьяга.

Ике ятим булдык, басуларда кундык —
Җил кермәде безнең арага.
Иңгә-иңне салып, ятим балачакның
Иң күбесе үтте далада.

Сугыш җиле тиде, ачлык еллар иде,
Ашамадык икмәк утырып.
Киндер янчык алып, таң чыкларын ярып,
Кайта идек башак тутырып.

Кар суларын эчтек, күпме кырлар кичтек
Яланаяк кырпак карларда.
Үтә җилле салкын, көзге яңгырда да
Сабышмадык уртак аһ-зарга.

Бала чакта безнең язмыш уртак иде,
Тик олысы уртак булмады.

Синең язмыш туктап, ялгыш юлда калды,
Ә минеке алга юл алды.

Алты дистә еллар гомер үтеп киткән,
Истән чыккан синең карашың.
Төшләремдә күрәм — һаман яланаяк,
Кар өстеннән атлап барасың.

Исләремә алып, сиңа шигырь язам —
Алты яшьлек ятим балага.
Хатирәләр били, айкап йөрәгемне,
Күзләремнән кайнар яшь ага.

Онытмадым сине, Камил, якын дустым,
Чәчләремә аклар якса да.
Без калдырган эзләр, кар сулары булып,
Күптән инде эреп акса да.

## Граннар як буенда

Әти-мәрхүм печән чаба
Граннар як буенда.
Белсәң иде шул чагында
Ни булды икән уенда.
Җемелдиләр таң чыклары
Таң кояшы нурына.
Изгелекләр теләгәндер
Бәлки газиз улына.

**Кушымта:**
Ий, әтием, бурычлымын
Сиңа гомерем буена.
Синең бүләк: җаным-тәнем,
Үсеп җиткән буем да.

Яңгырый чалгы тавышы —
Янавычы кулында,
Артыннан покосы кала
Ак чәчкәле болында.
Ак бәхеткә ирешмәде
Тырыш хезмәт кырында,
Ә шулай да бирешмәде —
Тугры калды юлында.

**Кушымта.**

## Өмет учагы

Ярты гасыр еллар үтеп китсәләр дә,
Сине эзли күңел кочагым.
Ярсу йөрәгемдә мәңге сүнмәс төсле
Дөрләп янган өмет учагым.

Мәхәббәттә өмет азгын нәфес түгел, -
Чын сөюнең сабыр-чыдамы.
Гомер язларыңның тәүге сөю хисе
Исләреңнән әллә чыгамы.

Сүрелерлек түгел өмет дигән күмер,
Янганда да көзге учагым.
Гомер юлларымда бәлки өмет үзе
Каршы алыр җәеп кочагын.

## Югары оч – Түбән оч

«Очып» кайткан авылымның
Урман аша юллары.
Югары очтан Түбән очка
Сузылган урамнары.

**Кушымта:**

Югары оч, түбән оч,
Җәйге кошым — сандугач,
Очкынып гармуным сайрый,
Уйнап үткән урамнарын
Җәен-кышын сагынгач.

Истән чыкмый авылымның
Тузан очкан юллары.
Еллар аша очып кайта
Тальянымның моңнары.
**Кушымта.**
Сагынып уйный гармуным
Авылым урамнарын,
Югары очтан Түбән очка
Уйнап үткән елларын.
**Кушымта.**

## Сүрелде самавырым

Кайнап чыкты самавырым,
Өстәлемдә кәрәз бал.
Күршедә бер чибәр генә,
Күзем төшкән бичә бар.
— Әйдә, күрше, чәйгә, — диеп,
Чакырдым шул бичәне,
Җайлап-майлап чәйләр эчеп,
Үткәрергә кичәне.

— Күршекәем, зур рәхмәт, —
Диде миңа бу бичә. —
Бер эчәр җирем дә юк, — дип,
Өстәп куйды үзенчә.
Кире какты хөрмәтемне,
Чәй эчәргә кермичә,

Самавыр түгел --- йөрәкнең
Кайнаганын белмичә.

Әллә соңга калдым инде,
Кыюлыгым җитмичә,
Нигә кичектерми генә
Кермәдем икән кичә.
Диваныма сузылып ятып,
Каптым йөрәк даруын:
Кайнамый да, чыжламый да –
Сүрелде «самавыр»ым.

**Ай кызы**

Ай янында синең йолдыз,
Кулың сузып ал гына,
Көянтәле Ай кызына
Тиңлим сине, Альбина.
**Кушымта:**
Әй, Ай кызы Альбина,
Чәчем чалланган, димә,
Чәчкәләр булып атармын,
Әгәр дә булсаң миңа.

Әгәр җитмәсә буйларың
Йолдызыңны алырга,
Янып сүнмәс йолдыз булып
Төшәр идем алдыңа.
**Кушымта.**
Ай янында йолдыз булып
Калыр идем гомергә,
Синең утыңда янсам да
Калмас идем күмергә.
**Кушымта.**

**Йөгәнсез тай**

Айның якты нуры төшә
Тегермән буйларына.
Төнлә көткән тай көтүе
Гел керә уйларыма.
Яна усак — төнге учак,
Җилкән-чая балачак,
Менгән атым — йөгәнсез тай
Мәңге истә калачак.

Туенган тай, күктә йолдыз,
Уртасында тулган Ай,
Су буенда хәтфә тугай,
Таң аткач, сайрый тургай.
Чапкан атым — йөгәнсез тай,
Тезгене юк тыярга.
Истәлекле балачакны
Ничек истән җуярга.

«Йөгәнсез» бала чакларны
Охшатамын тайларга.
Кырыкмыш тайлар артыннан
Чапмадык без кайларга.
Әгәр алар Айга менсә,
Менәр идек Айга да,
Тотып, тайларга атланып,
Чабар идек анда да.

Кырык яшемне уздырып,
Тигез җирдә тайсам да,
Тайпылмас истән балачак,
Таякка таянсам да.

## Шәфкать туташларына

Бик еш кына юл тотамын
Дәвахәнә ягына,
Әллә бик картайдым инде —
Дәва житми жанына.
Әллә жылы житми микән
Бер өшегән жаныма,
Әллә берәр сер бар микән
Сүрелмәгән канымда.

Рәхимле шифаханә!
Рәхмәтледер ашлары,
Ак халатлы, ак калфаклы —
Шифалы туташлары!
Башым иеп, сезгә киләм —
Шәфкать туташларына,
Күпләр сезгә чират тора,
Чир төшсә башларына.

Тотып, чиремне беләсез,
Эч серемне күрәсез,
Туңар-туңмас йөрәгемә
Жылы шифа өрәсез.
Рәхмәт сезгә, ак күңелле
Шәфкать туташларына,
Ак бәхеткә ирешегез
Гомер максатларында.

## Яз килер минсез генә

Үтте ямьле язлар, үтте жылы жәйләр,
Житте инде салкын көзләрем
Исеп кенә киткән жәйге жилләр булып,
Калыр инде жирдә эзләрем.

Үтте инде язлар, очты көзге казлар,
Артта калды гомер җәйләрем.
Җылы якка очкан күчмә кошлар булып,
Кайтмас инде кире әйләнеп.

Минсез генә яңа язлар килер инде,
Яшьләр уйнар яшел тугайда.
Минсез генә күчмә кошлар кайтыр инде,
Күктә сайрар язгы тургай да.

## Сагынырсыз әле без киткәч

Сызып сагындыра безнең заманалар,
Язларыбыз үтеп көз җиткәч.
Бәлки сез дә шулай үткән языгызны
Сагынырсыз әле без киткәч.

Сагынырсыз әле сез дә безнең кебек,
Язларыгыз узып, боз киткәч.
Көзләрегез җитеп, узган замананы
Сагынырсыз әле без киткәч.

Сагынырсыз әле безне — күпсенмәгез,
Күп калмаган безнең гомерләр.
Без калдырган сүзләр сезнең
күңелләрдә
Күк күгәрчен булып гөрләрләр.

## Югалмаслар әле җырларым

Беләм – килер бер көн,
Төшәр караңгы төн,
Минем кояш сүнеп каралыр.

Туктап жылы каным,
Ходай өргән жаным,
Караңгыга кереп югалыр.

Үткән гомер юлым,
Сезгә язган җырым,
Гүрне үрләп җиргә таралыр.
Бәлки туган якның
Ярларына кайтып,
Җансыз каным тагын яралыр.

Югалмаслар әле
Язган шигырьләрем,
Таң җилләре булып исәрләр.
Бәлки язган җырым
Гүр чәчкәсе булып,
Гүрдән шытып җирдә үсәрләр.

Билгесезгә китеп
Җаным югалса да,
Җирдә калыр минем уйларым.
Калын туфрак аша
Бәлки ишетермен,
Җырларымның сагыш-моңнарын.

Юк, мин әле яшим
Олы өмет белән,
– Югалмас, – дип, язган җырларым.
Ходай биргән зиһен
Баштан таралмаса –
Талмас әле язу кулларым.

## ЭЧТӘЛЕК

бит
1. Без яшәгән еллар ........................................3
2. Аскын җире ..................................................4
3. «Кителеп» төште кояш ..................................5
4. Чатлы каен ....................................................6
5. Куяр идем заман һәйкәлен ............................7
6. Авылым сагышлары .......................................8
7. Мин бит гармунчы идем ................................9
8. Урман юллары ..............................................10
9. Төй кызлары ..................................................11
10. Төй буе сагышлары ......................................12
11. Бала чагым ..................................................13
12. Гармун белән хушлашу ................................15
13. Күршемә ......................................................16
14. Авылым кочагында ......................................17
15. Иркәмә .........................................................18
16. Апа белән җизнәмә .....................................19
17. Гөлсинә .......................................................20
18. Малай-шалайлар ..........................................21
19. Үлчәүчеләр ..................................................23
20. Тәртип чыбыгы ............................................24
21. Укытучым Алия апага ..................................25
22. Көтәдер аны каен .........................................26
23. Яшел борчак ................................................27
24. Дин кызлары ................................................28
25. Гадел мөселманга .........................................29
26. Уңган апа Инзилә ........................................31
27. Какы ............................................................32
28. Кыш Бабай ...................................................32
29. Кирпеч суга абыем ......................................34
30. Иреняргыч ...................................................35
31. Төбәк тау .....................................................36

32. Билгесез ахыр .....37
33. Ялгыз кеше .....38
34. Авырлыкны җиңдек без .....39
35. Гөлчәчәк .....41
36. Үзгәрде дөнья .....42
37. «Утырмакыз» .....43
38. Алия .....44
39. Тәүге сөю .....45
40. Соңгы кырау .....46
41. Таңчулпан .....47
42. Кырыгың .....48
43. Дамирга .....49
44. Туган көн .....50
45. Сабак .....50
46. Мәхәббәтне саклагыз .....51
47. Яңавылым .....52
48. Гомер мизгеле .....54
49. Бар да сигез номерлы .....55
50. «Нине» нитәргә кирәк .....56
51. Кемнедер көтә йөрәк .....57
52. Яр буенда учак яна .....58
53. Кайтам әле .....59
54. Әтием истәлеге .....60
55. Казый балтасы .....82
56. Күңелең бит яшь әле .....83
57. Күңелем бураннары .....83
58. Соңгы уйлар .....84
59. Кайтып барам .....87
60. Бисмилланы кушыгыз .....88
61. Заманым сагышлары .....89
62. Бастырык .....89
63. Кайттым туган ягыма .....91

64. Изге чишмә ....................................................92
65. Аңлый алмыйм ..............................................92
66. Кайда сез, каеннарым ....................................93
67. Яз бәйрәме ....................................................94
68. Агым суга йөзмәгез .......................................95
69. Кече елга урманы ..........................................96
70. Яшьлегем миләшләре ....................................97
71. Әйдә язык гариза ...........................................98
72. Ике бәла .........................................................99
73. Яшьлеккә кайтыйк әле ..................................100
74. Тагын, тагын кызыгыз ..................................101
75. Озату ...........................................................102
76. Тагын бер күрәм әле .....................................103
77. Миңа син рәнҗемә ........................................104
78. Олы-Елга .....................................................105
79. Уйна әле гармуныңны ...................................106
80. Юл чишмәсе ................................................107
81. Буйсынмаган мәхәббәт ..................................108
82. Тынмасын азан моңы ....................................109
83. Аркабаш тавы аша ........................................110
84. Менә сиңа аулак өй .......................................111
85. Кече абый ....................................................114
86. Сатучы кыз ..................................................115
87. Сөйгәнем юк янымда .....................................116
88. Нәзилә дигән идем ........................................117
89. Тик өзелмәсен ара .........................................117
90. Бер күрер өчен генә ......................................118
91. Быргы моңы .................................................119
92. Биек тау итәгендә .........................................120
93. Яшимен уйларымда .......................................121
94. Җиләкле җәй .................................................122
95. Кара мунча ...................................................123

96. Әтием чаналары ....................................123
97. Ялгызым кичәләре ................................124
98. Ак чәчкәле яланда ..................................125
99. Зинфирәкәй – зәңгәр күз .........................126
100. Ямансу ...............................................127
101. Кил, назым ........................................128
102. Килер әле бәхет көзләре .........................128
103. Резедалар ...........................................129
104. Төй буйлары ник боек .............................130
105. Кайда сез, якташларым ............................131
106. Төй буе авыллары ..................................132
107. Исемнән чыкмый Истәк ...........................133
108. Түгәрәк күл .........................................134
109. Бәлки безне искә алырлар ........................135
110. Кырык нәсыйхәт ....................................137
111. Җилкуар ..............................................143
112. Уйныймын гармунымны ............................145
113. Иске гармун ..........................................146
114. Дәртле гармун........................................147
115. Килми ташлап китәсе ..............................148
116. Гармунчы дусларыма ...............................149
117. Очты тәкә коега ....................................150
118. Көтәбез Яңа елны ....................................156
119. Ак чәчлеләр ..........................................158
120. Кем сагынмый туган якларны ....................159
121. Билгесез сабыйга ...................................161
122. Асбест каласы .......................................162
123. Олы-Елга – Базанчат ...............................163
124. Гәрҗе ...................................................164
125. Фаҗига. 1942 ел. ....................................166
126. Замана .................................................167
127. Чыганагым ...........................................168

128. Гомер юлым ....................................................169
129. Кабык бишек ....................................................170
130. Кара чыршы урманы ....................................171
131. Калган эшкә кар ява ....................................172
132. Килер әле язларым ....................................173
133. Үз юлыңнан атладың ....................................174
134. Ике ятим ....................................................175
135. Граннар як буенда ....................................176
136. Өмет учагы. ....................................................177
137. Югары оч -- Түбән оч ....................................177
138. Сүрелде самавырым ....................................178
139. Ай кызы ....................................................179
140. Йөгәнсез тай ....................................................180
141. Шәфкать туташларына ....................................181
142. Яз килер минсез генә ....................................181
143. Сагынырсыз әле без киткәч ....................................182
144. Югалмаслар әле җырларым ....................................182

**"Тац" редакциясе" муниципаль учреждениесендә эшләнде. Адресы: 618150, Пермь крае, Барда авылы, Куйбышев урамы, 26. Заказ №109. Тираж 200 данә.**

